• ӘҢГӘМӘ •
ХӘЛӘЛ – УЛ БЕЗНЕҢ ТОРМЫШЫБЫЗ
*4-5 бит*

• ГЫЙБАДӘТ •
НАМАЗГА ӨЙРӘНӘБЕЗ
*8 бит*

• ТАРИХ•
ХАБИБРАХМАН ШАКИР: МЕҢЛӘГӘН КҮЛЛӘР ИЛЕНӘ СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛ
*11 бит*

• ҮРНӘК ЗАТЛАР •
СӘГЪД БИНЕ ӘБИ ВӘККАС
*13 бит*




*№ 2 (307)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *раҗәб 1442*

*февраль, 2021*

# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ


# Раҗәб ае – мәрхәмәтлелеккә юл



*Раҗәб – мөселман тәкъвименең 7 нче ае. Гарәп теленнән «раҗәб» сүзе «изгеләштерү» дип тәрҗемә ителә. Гарәпләр бу айны олуглап каршы алганнар. Бу айда барлык хәрби походлар туктатылып торган. Раҗәб аеннан соң – шәгъбан, ә аннан соң Рамазан ае килә. Шуңа күрә дә бу айда уразага әзерлекләр башлана. Мөселман кешесе үзенең гыйбадәтләр санын арттыра.*

*Дәвамы 6 нчы биттә*

# *«Ислам. Беренче адымнар»* проекты янәдән ачылды



13нче февральдә Казанда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең иң мөһим проектларыннан берсе – намаз укырга өйрәтү һәм Ислам нигезләре белән таныштыру буенча «Ислам. Беренче адымнар» дип аталган кыска вакытлы курслар кабат үз эшен башлап җибәрде. Татарстан мөфтиятенең конференц-залында җиденче тапкыр укуларны ачып җибәрү тантанасы узды. Дәресләргә барлыгы 120 кеше язылды. Курсларга йөрүчеләр 7 дәрестә (атнасына бер тапкыр) намаз уку күнекмәләрен һәм ислам дине нигезләрен бушлай үзләштерә алачак. Шунысын билгеләп узарга кирәк: намаз уку дәресләренә килүчеләр арасында гаиләләре белән язылучылар да бар.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль үсеш бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова шәкертләргә аңлатканча, һәр изге эшне Аллаһы сүзеннән башларга кирәк. «Безнең күркәм Коръән – Аллаһы сүзләре», – диде ул.

Алга таба оештыручылар дәресләрнең тәртибе, уку вакыты һәм урыны, программа, мөгаллимнәр белән таныштырды. Беренче дәрестә катнашучыларга нәзарәтнең дәгъват бүлеге хезмәткәре Гали хәзрәт Ибодов нәсыйхәт сүзләрен җиткерде һәм кыска вәгазь белән чыгыш ясады.

Ул бу дөньяда яшәүнең мәгънәсе, кешенең бу дөньяга килүенең максаты, мөселманның сыйфатлары турында сөйләде. Хәзрәт катнашучыларга ни өчен шәригать кушканча яшәргә кирәклеге, мөселман кешесе нинди булырга тиешлеге, бу дөньяның һәм Ахирәтнең төп аермалары нидән гыйбарәт булуы, җәннәт һәм җәһәннәм төшенчәләре турында аңлатмалар бирде.

– Ислам дине кешеләрне дөньяда һәм Ахирәттә бәхетле итә. Ислам динен Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, бөтен кешелеккә җиткерсен өчен, җибәргән. Аллаһы Тәгаләгә буйсынырга теләгән кеше Ислам дине кануннарына буйсынып яшәргә тиеш. Бу дөньяга килгәч, адәм баласы күп сынаулар белән очраша һәм Раббысын оныта. Дөнья белән Ахирәт арасында 10 аерма бар, – дип билгеләп үтте һәм аларны санап, аңлатмалар биреп узды.

Вәгазь тәмам булганнан соң, ирләр Галиев мәчетендә, ә хатын-кызлар нәзарәтнең конференц-залында белем алырга керешә. Оештыручылар укучыларга татар һәм рус телләрендә уку өчен кирәк булган материаллар таратты. Беренче дәрес тәһарәт алу темасына багышланды. Катнашучылар өйлә намазы алдыннан белемнәрен практик яктан да ныгытты – остазларына дөрес итеп тәһарәт алып күрсәтте. Аерым алганда, укучылар, «Ислам. Беренче адымнар» проектында катнашып, алдагы дәресләрдә намаз уку тәртипләрен өйрәнәчәк, гакыйдә фәненә караган төп төшенчәләр, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы, хәләл-харам, хаҗ, уразаның фазыйләтләре һәм тәртипләре белән танышачак. Укулар 27нче мартта, татар халкының гореф-гадәтләренә нигезләнеп, Коръән ашы белән тәмамланачак. Әлеге дәресләргә теләгән һәркем йөри ала. Яшь буенча чикләүләр юк.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты мөфтият тарафыннан беренче тапкыр 2018 елда дәгъват эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырыла башлады.

Әлеге проект 5 ел дәвамында мәчет каршындагы курсларга йөрергә вакыты булмаганнарга гыйбадәт нигезләрен үти башларга мөмкинлек бирү өчен махсус оештырылды. Алты сезон дәвамында әлеге курсларда 580 кеше белем алды һәм намазга басты.

Дәресләр шимбә көннәрендә иртәнге сигездән (08.00) көндезге бергә кадәр (13.00) Казанның Галиев мәчетендә (Габдулла Тукай урамы, 40) узачак. Белем бирү татар һәм рус телләрендә алып барылачак. «Ислам. Беренче адымнар» проектында катнашучыларның барысын да бүләкләр көтә.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# «Зәкят» хәйрия фонды сукбайлар һәм мохтаҗларга кайнар ризык таратуны дәвам итә

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды йортсыз-җирсезләр һәм мохтаҗларны урамда бушлай ашатуын дәвам итә. Сукбайлар һәм мохтаҗлар һәр җомгада яңа гына пешеп чыккан кайнар ризыклар ашый алачак.***

Нәзарәтнең мондый хәйрия чараларында катнашучылар – авыр хәлдә калган йортсыз-җирсезләр, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр, өлкән яшьтәге ялгыз карт-карчыклар. Аларга беренче һәм икенче ризыклардан итле аш һәм пылау, ипи, чәй тәкъдим ителә. «Зәкят» хәйрия фонды волонтёрларны әлеге акцияне оештыруда ярдәм итәргә чакыра. Теләге булган һәркем бу изге эштә катнаша ала. Моның өчен 225-33-22 телефоны буенча шалтыратырга кирәк.

Моннан тыш, Казанда ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешмасы белән берлектә авыр хәлдә калган кешеләргә ярдәм итү максатыннан, 3 пункт эшләп килә. Кешеләрне кайнар аш һәм кием-салым белән тәэмин итү буенча әлеге пунктларга Симонов, 3нче йорт адресы буенча «Рәхмәтулла» мәчете территориясендә һәм Авангардная урамы, 58 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт каршында булачак мәчет урынында һәм Борһан Шаһиди урамы, 26нчы адресы буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Мохтаҗларга бушлай ярдәм» комплексы белән хезмәттәшлеге 2014 елдан бирле «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» автономияле коммерцияле булмаган оешма белән арасында төзелгән килешү нигезендә алып барыла. «Мохтаҗларга бушлай ярдәм» комплексы эшчәнлеге күренекле җәмәгать эшлеклесе Азат Гайнетдинов җитәкләгән Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла.



■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Галимҗан Барудиның тууына 164 ел

Мәшһүр дин галиме, җәмәгать эшлеклесе, күренекле педагог, Үзәк Диния нәзарәтенең мөфтие Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Баруди (Галиев) 1857 елның 17нче февралендә Казан өязенең Кече Кавал авылында (хәзерге Татарстанның Биектау районында) сәүдәгәр гаиләсендә туа. 1860 елда гаилә Казанга күчеп килә. Мөхәммәтҗан Галиев ихласлы һәм укымышлы кеше буларак, үз балаларына тиешле белемнәрне бирер өчен, малын һәм көчен кызганмый. 1862 елда Галимҗанны Апанай мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Бу мәдрәсә XVIII гасырның 70 нче елларында барлыкка килә һәм Апанай мәчете белән берлектә эшли. Үз чорында бик көчле мәдрәсәләрдән санала. Биредә ул Саләхетдин хәзрәт Исхаковта белем ала, мөстәкыйль рәвештә күп китаплар укый. Тырышлыгы, сәләте зур булу сәбәпле, 1871 елда башлангыч сыйныфларда дәресләр бирә башлый. 1875 елда, белемен күтәрү өчен, 18 яшьлек Галимҗан Урта Азиягә юл тота. Анда җиде ел укып, дини һәм дөньяви фәннәрне үзләштерә.

1882 елның 15нче июнендә яшь галим Казанга күп китаплар һәм кулъязмалар белән кайта. Бу йөкнең авырлыгы якынча 650 кг, бәясе 5-6 мең була. Галимҗан Баруди гомер буе китап җыю белән шөгыльләнә. 1920 елда Галимҗан Баруди үзенең уникаль китапханәсен дәүләткә тапшыра. Бу байлык хәзерге көндә Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана.

1882 елның 28нче октябрендә Галимҗан хәзрәт Иске Татар бистәсенең бишенче Җәмигъ мәчетенең (хәзерге Тукай урамындагы Галиев мәчете) имамы итеп билгеләнә. Мәчет каршында дәресләр бирә. Тиздән Галимҗан хәзрәтнең үз мәдрәсәсендә белем бирү мөмкинлеге барлыкка килә. 1882 елда әтисе тарафыннан мәдрәсәнең бер катлы бинасы төзелә. Әлеге мәдрәсәдә Галимҗан Баруди 1883 елда беренче дәресләр бирә башлый. Бу мәдрәсә аңа нигез салган Мөхәммәтҗан исеменә нисбәт ителеп «Мөхәммәдия» исемен ала. Шәкертләрнең саны елдан-ел арта бара. Шуңа күрә Мөхәммәтҗан Галиев танылган татар сәүдәгәрләре Әхмәтҗан Сәйдәшев һәм Габдулла Үтәмишев белән мәдрәсәне зурайта. 1886 елда мәдрәсә бинасының өченче каты салына. Мәдрәсәнең даны киң тарала.

1886 елда Галимҗан Баруди изге Мәккә шәһәренә хаҗ кылырга бара. Бу сәфәрдә ул Истанбулны, Мисырны зиярәт итә, галимнәр белән очраша, белемнәрен арттыра.

Казанга кайткач, Галимҗан хәзрәт иске иҗек ысулын аваз ысулына алыштыра, уку-укыту программасын камилләштерә, яңа дәреслекләр, китаплар яза. Галимҗан Барудиның беренче китабы «Гыйльм әт-тәүхид» («Аллаһының берлеге турында гыйлем») 1890 елда басыла. 1891 елда, яңа ысул белән укыту өчен, «Сәвадхан» («Гыйлем иясе») исемле әлифба төзи. Бу китап яңа ысул белән төркичә язылган беренче әлифба булып санала һәм 1891-1915 елларда унике тапкыр басыла. Шул ук елда аның арифметика буенча «Нәмунәи хисаб», ислам нигезләре буенча «Китаб әс-салават» («Догалар китабы»), «Бәдә әл-мәгариф» («Белемнәрнең нигезе») «Сад пәнд» («Йөз нәсыйхәт») дигән хезмәтләре дөнья күрә.

1901 елда Галимҗан Барудиның зур абруен искә алып, Габдулла Үтәмишев, Әхмәд Хөсәинов һәм башка татар байларының ярдәме белән мәдрәсәнең өч катлы таш бинасы салына (хәзерге Тукай урамы, 34а). Мәдрәсә заманча җиһазландырыла, шәкертләр өчен барлык шартлар тудырыла. Мәдрәсәнең ишегалдында ашханә, авырулар өчен хастаханә, итек-читек, кәвеш төзәтү, агач эше, китап төпләү остаханәләре булдырыла.

1906-1908, 1913-1917 елларда Галимҗан Баруди татар телендә «Әд-дин вәл-әдәп» исемле фәнни һәм дини журнал чыгара.

1908 елда Галимҗан хәзрәтне панисламизмда гаепләп, ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәрәләр. Анда 4 ай яшәп, Эчке эшләр министрлыгыннан чыгу өчен рөхсәт ала. Чит илләргә сәяхәт кылып, Вена, Будапешт, Истанбул, Димәшкъ, Бәйрут кебек шәһәрләрдә булып кайта.

Галимҗан Баруди сөргендә булган вакытта, энесе Габдрахман хәзрәтнең ярдәме белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе эшен дәвам итә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең даны бөтен Рәсәй мөселманнары арасында тарала. Биредә татар яшьләре генә түгел, башкорт, казакъ, кыргыз, кумык һ. б. төрки халык вәкилләре дә гыйлем алырга омтыла. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе 1918 елга кадәр эшләгән.

Галимҗан хәзрәт Баруди Рәсәй мөселманнарының сәяси тормышында да актив катнаша. Ул 1906 елның гыйнвар һәм август айларында узган Рәсәй мөселманнарының 2нче һәм 3нче корылтайлары эшендә катнаша. «Иттифакъ әлмөслимин» мөселман фиркасе Үзәк комитетының әгъзасы итеп сайлана.


1917 елның май аенда Мәскәүдә I Бөтенрәсәй мөселман корылтае уза. Күпчелек тавыш белән Рәсәй мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте мөфтие итеп Галимҗан Баруди сайлана. Әмма Галимҗан хәзрәт үзе бу турыда Чимкент шәһәрендә булганда белә.

Казанга кайткач, Галимҗан Баруди мөфти вазифасы турында туганнары һәм якын кардәшләре белән киңәшә, аларның фикерләрен тыңлап, бу җаваплы вазифаны алырга риза була.

Галимҗан хәзрәт, мөфти буларак, күп хезмәт башкара, халыкка армый-талмый хезмәт итә, үлеме дә изге юлда йөргәндә була. Мөфти хәзрәтләре 1921 елның 6 декабрендә Мәскәү каласында ачларга ярдәм күрсәтү эшләре белән командировкага барган чакта вафат була. Аны Казанга кайтаралар һәм Яңа Татар бистәсе зиратында дәфен кылалар.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Нәзарәтнең шәригать белгечләре сертификацияләнгән экспертлар булдылар




Казан шәһәре казые, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Шәригать мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбарәков һәм әлеге бүлек белгече, ислам фәннәре докторы Идрис хәзрәт Кыёмов ислам финанслары өлкәсендә сертификацияләнгән экспертлар булуга ирешә. Бу хактагы сертификатны Бәхрәйн шәһәрендәге ислам финанс учреждениеләре өчен бухгалтерлык исәбен алып баручы һәм аудит уздыручы AAOIFI оешмасы биргән. AAOIFI – ислам финанс учреждениеләре өчен бухгалтерлык исәбен, аудитны, идарә итү, этика һәм шәригать стандартларын үстерү оешмасы.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте белгечләре AAOIFI оешмасының Рәсәйдәге имтихан бирү үзәгендә белем алды. Әлеге үзәк Рәсәй ислам институтының Рәсәй ислам икътисады һәм финанслар үзәге һәм Ислам финанс оешмаларының бухгалтерлык исәбе һәм аудиты оешмасы (AAOIFI) белән килешү кысаларында 2019 елда оештырылган иде. AAOIFI белән хезмәттәшлек турындагы килешүгә Рәсәйдә беренче тапкыр кул куелды. Бу Рәсәй белгечләренә ислам финанслары өлкәсендә, чит илгә чыкмыйча гына, эксперт булырга мөмкинлек бирә.

Рәсәй ислам икътисады һәм финанслары үзәге 2008 елның октябрендә Рәсәй ислам институты базасында Ислам үсеш банкы (Согуд Гарәбстаны Корольлеге) һәм Куала-Лумпур бизнес-мәктәбе (Малайзия) белән берлектә гамәлгә куелды.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Хәләл – ул безнең тормышыбыз

*Расүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәллəм: «Кеше тәненә харам керсә, 40 көн буе кылган догасы кабул булмас», – дип әйткән (Имам Әт-Табәрани хәдисләр җыентыгыннан). Без еш кына хәләл ризык, хәләл ит төшенчәләрен дөрес аңлап бетермәү күренешен күзәтәбез. Үзебезнең дә, балаларыбызның да хәләл белән генә тукланып яшәвебезне теләсәк тә, кайбер авырлыклар алдында калырга мөмкинбез.*



**Хәләл белән харамны ничек бутамаска? Ни өчен хәләл ризыкка өстенлек бирү мөһим? Харам ризык ашауның куркынычы нидә? Бу һәм башка сораулар белән ТР МДНнең Хәләл комитеты җитәкчесе, Казан шәһәренең Габдерәхим Утыз имәни мәчете имам-хатыйбы Ирек хәзрәт Җиһаншинга мөрәҗәгать иттек.**

### Хәләл мәсьәләсен хәл итеп була

***Хәзрәт, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Иң беренче чиратта, әңгәмәбезне күпләрне борчыган актуаль сораудан башларга булдык: балалар бакчаларында, мәктәпләрдә хәләл туклану мәсьәләсе ничек хәл ителә?***

**– Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин. Вә әлгакибәтуль лил-мүттәкыйн. Вә ләә гудуәәнә иллә галәẓ-ẓаалимиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.**

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз булса иде һәм дә Аның сөекле хәбибе – Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә салават-шәрифләребез ирешсә иде. Барыгызны да Аллаһының сәламе вә рәхмәте белән сәламлим. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Без, хәләл комитеты буларак, «Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» дигән оешма белән эш алып барабыз. Шул эш барышында кешеләрдән: «Хәзрәт, без балаларыбызны балалар бакчасына, мәктәпкә бирергә телибез. Әйтегез әле, анда ризык хәләлме икән?» – дигән сораулар килә. Без шулай дип җавап бирәбез: балаларын бакчага, мәктәпкә бирергә теләгән ата-ана андагы вәзгыятьне карарга тиеш. Хәләл туклану мәсьәләсен хәл итүдә, ата-аналар комитеты әгъзаларының балалар бакчасы мөдиренә, хәләл туклануны булдыруны сорап гариза язулары кирәк. Имзалар никадәр күп булса, шулкадәр яхшырак, билгеле. Әйтик, әгәр сез балагызны балалар бакчасына биргәндә, бары тик үзегез генә туклануның хәләл булуын телисез икән, моны үз көчегез белән генә булдыру – четерекле мәсьәлә булып кала. Шуңа күрә, никадәр күбрәк ата-аналар бу сорауны күтәреп чыгып, әйдәгез әле, моны бергәләп хәл итик, дип тотынса, балалар бакчасы мөдиренә мөрәҗәгать итеп, имзалар җыйса, шулкадәр җиңелрәк һәм хәерлерәк булачак. Һәм шул мөрәҗәгать нигезендә, балалар бакчасы мөдире Мәгариф идарәсенә чыгып, безнең шәһәрнең яки муниципалитетның балалар бакчасына хәләл ризыкларны булдыруыгызны үтенәбез, дип гариза язарга һәм монда ата-аналарның имзаларын куярга тиеш. Шул рәвешле, Мәгариф идарәсе Департаментка чыгып, әлеге балалар бакчасында хәләл ризыклар булдыруыгызны сорыйбыз, дип мөрәҗәгать итәләр. Әлеге хат Мәгариф министрлыгына да җибәрелсә, яхшы булыр.

Шунысы кызганыч, һәрбер балалар бакчасына, мәктәпкә дә хәләл ризык килми.

«Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты»нда бөтен вәзгыять тендер юлы белән башкарыла. Мәсәлән, авыл-хуҗалыгында эш алып бара торган фермерлар, ит комбинатлары тәкъдим иткән бәяләр арасыннан Департамент иң арзан дигәнен сайлап ала. Һәм шул азык-төлек – балалар бакчаларына, мәктәпләргә җибәрелә.

Ярымфабрикатларның ясалу рәвешен дә карап үтик. Әйтик, бездән таныклык алган чимал җитештерү оешмасы, үзләренең продукциясе белән Департаментка килә. Департаменттан безгә – Хәләл комитетына шалтыратып, иртәгә чималны эшкәртәчәкбез, дип хәбәр итәләр. Безнең намаз укый торган мөселман технологыбыз анда барып, бөтен тәртипне: чисталыкны, өстәлләрне, җиһазларны карап, тикшереп, килгән чималны эшкәртә башларга рөхсәт бирә. Мәсәлән, сояктән аерылган, туңдырылган рәвештә сыер ите китерелә, аны яңадан эретеп ярымфабрикатлар: фарш, гуляш өчен әзерлекләр ясыйлар. Һәм аларны Хәләл комитеты тамгасы куелган пакетларга тутырып, мәктәпләргә, балалар бакчаларына җибәрәләр.

### «Бисмилләһи Аллаһү әкбәр», – дип чалынуы мөһим

Безнең балалар бакчасында, мәктәпләрдә хәләлме икән, дигән сорауны безгә еш бирәләр. Әлеге сорауга без бу рәвешле җавап бирәбез: «Хөрмәтле әти-әниләр, әби-бабайлар, балаларыгыз, оныкларыгыз йөргән мәктәпләргә, балалар бакчаларына барыгыз. Андагы ашханәнең мөдире, пешекчесе белән күрешеп, сөйләшеп, минем балам бу мәктәпкә яки балалар бакчасына йөри. Монда дөрестән дә хәләлме икән?» – дип сорагыз, белешегез дип әйтәбез. Әгәр алар: «Әйе, дөрестән дә менә безгә «Азык-төлек һәм социальтуклануденпартаменты»ннан «Хәләл» тамгасы булган ризыклар килә, дип әйтсәләр, ата-аналар тынычланып кала.

Безгә бик күп мөрәҗәгатьләр килеп тора: «Хәзрәт, безнең балалар бакчасында, мәктәптә дә хәләл туклану булса иде», – дип сорыйлар. Ләкин чимал җитми, продукция тендер юлы белән алына. Хәләл комитеты буларак, без үзебезнең фермерларыбызны, шул чималны җитештерүчеләрне тәкъдим итәбез, ләкин алар билгеле бер бәя кысаларына керә алмый. Шул сәбәптән, иң беренче чиратта, татар компоненты булган балалар бакчасына, мәктәпләргә һәм гимназияләргә генә хәләл ярымфабрикатлар китерелә.

Шуны әйтергә кирәк: Департамент әзерләгән ризыкларда дуңгыз һәм сарык ите юк, чөнки балаларның рационында дуңгыз һәм сарык ите авыр ризык булып санала. Шуңа күрә сыер йә тавык итләре генә китерелә. Әммә, белүебезчә, аларны да карарга кирәк. Мәсәлән, сыер ите дә, тавык ите дә «Бисмилләһи Аллаһү әкбәр», – дип чалынмаса, харам була. Без әлеге мәсьәләләргә карата игътибарлы булырга тиеш.

### Халык хәләл турында аз белә

**– Хәзрәт, тагын шундый сорауга да җавап бирсәгез иде: ризык хәләл булсын өчен, нинди шартлар үтәлергә тиеш?**

– Кызганычка, халык хәләл белән бәйле булган мәсьәләләрне бик аз белә. Шуңа күрә дә, без – хәзрәтләр төрле очрашуларда хәләл турында сөйләргә тырышабыз. Мәсәлән, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримнең «Әл-Маидә» сүрәсендә безгә биш әйберне харам кылганлыгы турында әйтә.

**Беренчесе:** безгә үләксә итен ашау харам кылынган. Мәсәлән, сыер, тавык, үрдәк – нинди хайван булса да, үз үлеме белән яки егылып төшү аркасында үлгән икән, яки ток белән бәреп үтерелгән икән, бу хайваннарның ите үләксә була һәм аны ашау катгый рәвештә тыелган.

**Икенчесе:** Раббыбыз безгә кан ашауны, кан белән бәйле ризыкларны харам кылды. Әйтик, балаларга кечкенә вакытларында әниләр, дәү әниләр гематоген бирәләр иде. Гематоген үгез каныннан ясала. Шуңа күрә, ул харам булып санала. Әгәр дә без балаларыбызның намаз, Коръән укырга өйрәнүләрен, догалар белүләрен, дөрес фикер йөртүләрен телибез икән, аларны бары тик хәләл булган ризыклар белән тукландырырга кирәк.

**Өченчесе:** Раббыбыз безгә, дуңгыз итен һәм аның белән бәйле булган ризыкларны харам кылды. Дуңгызның ите, тиресе нәҗес булып санала. Әгәр дә бу хайванга карасак, кызыклы фактка тап булабыз: башка хайваннар тирләгән вакытта, аларның 90% тирләре бүленеп чыгып, 10%ы организмында кала. Ә менә дуңгызда бу процесс киресенчә: аның 90% тире тәнендә кала, бары тик 10 %ы гына бүленеп чыга. Һәм шул тирләү процессы яхшы узсын өчен, ул үзенең пычракларында ауный. Хикмәт буларак бары тик бер хайван: дуңгыз гына әлеге үзенчәлеккә ия. Димәк, аның барлык зарарлы матдәләре, пычраклары тәнендә кала. Бу итне ашаган кешеләрнең үзләренә күпме зыян салуын күз алдына китерик.

**Дүртенчесе:** Раббыбыз безгә Аллаһы Тәгалә исеме белән чалынмаган хайваннарның итләрен харам кылды. Әлбәттә безгә сыер ите дә, каз ите дә, тавык ите дә, дөя ите дә ашарга ярый. Әмма әгәр бу хайваннар «Бисмилләһи Аллаһү әкбәр» дигән сүзләр белән, мөселман кешесе тарафыннан, үткен пычак ярдәмендә чалынмаса – бу ит безгә харам була. Бүгенге көндә без – хәзрәтләр, мәҗлесләргә барган вакытта, күп очракта, бу ит хәләлме, дип сорыйбыз. Безгә апалар, әбиләр: «Без бу итне авылдан алып килдек», – дип әйтәләр. Әмма шунысын белик: авылдан алып килгән һәр ит тә хәләл дигән сүз түгел. Аны кем чалган? «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр», – дигән сүзләрне әйткәнме? Кулындагы пычагы үткен булганмы? Боларның барысы да мөһим. Әгәр, дөрестән дә, бу тәртипләр үтәлгән булса, тыныч күңел белән, әйе, бу ит хәләл дип, әйтә алабыз.

Кызганычка, бүгенге вакытта җитештерүчеләр тарафыннан бик күп алдаулар була. Кайбер апалар мондый очракларда: «Хәләл булмаса, гөнаһысы саткан кешегә булыр, безгә булмас», – дип әйтә. Әмма бу ялгыш фикер. Әлбәттә, алдаган кешегә гөнаһысы булыр. Әмма бу харамны ашаган кешенең 40 көн буена кылган догасы кабул булмас.

Димәк, әгәр хайванны чалу рәвеше харам рәвештә башкарылса, бу ит хәләл була алмый. Әгәр мөселман кешесе хәмер эчеп хайванны чалса, бу ит харам була. Шулай ук «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр» сүзләрен тавыш белән әйтмәсә дә, бу ит харам була. Боларны белү мөһим.

Без һәрдаим шуны күңелебездә тотарга тиешбез: без беркөнне бу дөньяга килдек, ике тамчы судан барлыкка китерелгән идек һәм билгеле бер көн җиткәч, бу дөньядан китәчәкбез.

**Бишенчесе:** Раббыбыз безгә ерткыч хайваннарның һәм кошларның итен харам кылды. Мәсәлән, аю, бүре, төлке кебек хайваннарның, бөркет кебек үткен тырнаклы кошларның итләре безгә харам булып тора.

Мәсәлән, аучылар ауга барып, аюны, бүрене, төлкене үтереп, шул хайваннарның итләрен ашаса, молекуляр дәрәҗәдә шул хайванга әвереләләр, ягъни үзләре дә ерткыч кебек булалар. Әгәр дә кеше дуңгыз итен ашаган булса, ул молекуляр дәрәҗәдә аңа әверелә. Югарыда Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен искә алган идек. Пәйгамбәребез: «Әгәр кеше белеп, харам ризыкны ашаган булса, Аллаһы Тәгалә 40 көн дәвамында аның кылган догасын кабул кылмый», – дип әйткән. Бу – намаз укучыларга, ураза тотучыларга, изге гамәл кылучыларга аяныч хәл һәм без бу мәсьәләгә бик җитди карарга, ашаган ризыгыбызга бик игътибарлы булырга тиешбез. Димәк, без нәрсә ашыйбыз – шуңа әвереләбез.

## لزيز «Лэзиз» хәләл дигән сүз түгел

Хәләл лайфстайл, хәләл тормыш рәвеше, дип сөйлибез. Мәсәлән, иртән торып суыткычыбызны ачуга, андагы ризыкның хәләл булуы тиешле. Шул ук сырларның составында «сычужный фермент (сычуг) животного происхождения» дигән язу булып, анда «Хәләл» тамгасы тормаса, әлеге сыр харам санала. Әгәр инде сырда «фермент (сычуг) микробного происхождения» дип язылган булса, димәк, хәләл. Боларны белү мөһим. Казылыклар белән дә шулай ук. Аларны сайлаганда да игътибарлы булу кирәк. Казылыкның тышлыгында «мөселманча» яки «лэзиз», дип язылган тамгалар яисә анда ай рәсеме, манара рәсеме куелу аның хәләл булуын аңлатмый. Бары тик «Хәләл» тамгасы булган очракта гына казылыкны шикләнмичә алырга мөмкин.

## Харам ризыкны ташларга ярый

Кайбер әбиләр: «Хәзрәт, менә мин намаз укыйм, әмма белмичә кибеттән харам булган казылыкны сатып алып кайтканмын. Аны нишләтергә инде?» – дип сорыйлар. Һәм кайберләре: «Хәзрәт, менә ялларда оныкларым кайталар, аларга бирәм инде, намаз укыгач, миңа харам ризык ашарга ярамый», – дип, бик тә ялгыш фикер йөртәләр. Бу – бигрәк тә зур хата. Кеше үзе намаз укыгач, балаларының, оныкларының да намаз укуын теләргә тиеш. «Ул балалар намаз укымый, димәк аларга ашатырга ярый. Ташлаганчы, аларга ашатабыз», – дип әйтү – ялгыш фикер. Әмма шуны белик: бу ризык харам һәм аны ташларга ярый, ә башка кешегә бирү катгый рәвештә тыелган гамәл. Бу ризыкны йә ташларга, йә, берәр хайван алып китәр әле, дип, кеше күрми торган җиргә куярга кирәк. Хәтта ул харам ризыкны йорт хайваннарыбызга да ашатырга хакыбыз юк. Бары, безгә харам булган ерткыч хайваннарга гына бирә алабыз.

Кызганычка, шундый хәлләрне дә ишетергә була. Бер әби килеп: «Хәзрәт, менә мин базардан арзанга гына тавык ите алган идем, әмма ул хәләл түгел иде. Мин өйгә кайттым да өч тапкыр, «Бисмилләһи», – дип, пычак белән шул тавыкны кисеп алдым. Болай эшләсәм, хәләл буламы?» – дип сорыйлар. Без бу очракта: «Бу ит хәләл була алмый, ул – харам. Әлеге ит хәләл булсын өчен, ул тавыкны «Бисмилләһи, Аллаһү Әкбәр», – дип чалулары кирәк иде», – дип җавап бирәбез.

## Хәләллек ризыкка гына кагылмый

Кайвакытта бездән алкогольсез сыралар хакында сорыйлар. Кызганычка, кайбер «псевдохәләл» оешмаларның сыраны хәләл дип әйтүләре дә булды. Шуңа алданып, кешеләр анда алкоголь 0% дип тора, димәк, эчәргә ярый, диләр. Беренчедән, алкоголь бөтенләй юк, дип язсалар да, анда барыбер күпмедер күләмдә ул булачак. Икенчедән, гореф-гадәтебез буенча, бу бер дә матур күренеш түгел. Күз алдына китерегез, әгәр берәр хәзрәтнең кулында мондый сыра күрсәгез, кайсыгызның аны үз өенә ашка чакырасы килер икән? Яки кайсыгыз аның артына басып намаз укырга теләр?

Хәләл ризыкка гына кагылмый. Хәләл – ул бөтен тормышыбыз, яшәү рәвешебез. Хәтта яшьләр никахлашканда да, алардан хәләл җефетлеккә риза булып бардыңмы, риза булып алдыңмы, дип сорала.

## Харам ашасак, догабыз кабул булырмы?

Хәләл белән генә тукланып яшәү мөһим, чөнки бу соңгы сулышларыбызның нинди булуына да бәйле. Кайвакытта безгә шалтыратып: «Хәзрәт, менә ашыгыч ярдәм машинасы килеп китте, якыныбызга берни белән дә ярдәм итә алмыйбыз, килегез», – диләр. Килсәк, үлем түшәгендә ятучы кеше йортым, машинам, акчаларым кемгә кала дип, җан бирә алмыйча ята.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ» сүзләрен әйтүче җәннәткә керер», – дип әйткән. Без, йортыбызга кергәндә, аны ачкыч белән ачып керәбез. Машинага утыргач, кузгалып китәр өчен, ачкыч кирәк. Нәкъ шулай ук җәннәтнең һәм гүрнең дә үз ачкычы бар. Ул «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ» сүзләре.

Соңгы сулышларыбызда әлеге сүзләр булуын телибез икән, ул вакытта безнең ризыгыбыз, киемебез, әйткән сүзләребез хәләл булырга тиеш. Расүлебез бер хәдисендә болай дигән: «Бер кеше чүлдә кулларын күтәреп «Йә Рабби, йә Рабби», – дип дога кыла, Аллаһыга ялвара, әмма аның догасы кабул булмый, чөнки ашаган ризыгы – харам, кигән киеме – харам. Ничек Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итсен?» Әгәр без Аллаһының рәхмәтенә, бәрәкәтенә ирешергә телибез икән, ризыгыбызда, гамәлләребез дә, фикерләребез дә, сүзләребез дә хәләл булырга тиеш, иншә-Аллаһ.

Вә салләллаһу галәйһи сәййидинә Мүхәммәдин вә галә әәли әсхаабиһи вә әҗмәгыйн. Вә әлхәмдүлилләһи раббил галәмиин.

**– Ирек хәзрәт, файдалы һәм бик актуаль әңгәмәгез өчен, Аллаһының рәхмәте булсын. Сезгә эшегездә уңышлар телибез. Аллаһы Тәгалә башкарган хезмәтегездән риза булып, ике дөнья бәхетенә ирешүегезне насыйп кылсын.**

■ Әңгәмәне
**Айсылу ЮЛДАШЕВА** оештырды

# Раҗәб аеның фазыйләтләре



*Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы исеме белән башлыйм. Аллаһы Тәгалә вакытны бер дә туктап тормый, һәрвакыт хәрәкәттә булган берәмлек итеп яраткан. Көн артыннан көн килеп, айлар елларга әйләнеп, вакыт уза, дәверләр кичелә, заманнар үзгәрә. Менә тагын фазыйләтләргә бай бер ай – раҗәб ае башланды. Шул айның өстенлекләрен искә төшереп узыйк.*

Һәрвакыт белем алып тору, белгәнне искә төшерү – мөселманның асыл сыйфатыдыр. Раббыбыз Аллаһы Үзенең Изге Китабында болай дигән:

***«Әйт: «[Исламны] Белгән [һәм белгәне белән яшәгән] кешеләр белән [хакны] белмәгән [шул сәбәпле, наданнарча эш йөрткән һәм адашу эчендә югалып калган] кешеләр тиң була аламы? Аек акылларга ия кешеләр генә үгетләнә».***

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

Әйдәгез, Ислам динебезне яхшы белүче һәм белгәннәребез белән гамәл кылучылар рәтеннән булыйк, җәмәгать!

Билгеле ки, раҗәб, шәгъбан һәм Рамазан айлары изге айлардан санала. Алдагы икесе Рамазан аена әзерлек – үз-үзеңне рухи һәм физик яктан чыныгуга, чистарынуга, үзгәрүгә әзерлек вакыты булып тора. Раҗәб ае җиттеме, димәк, изге Рамазан аена бер адым тагын да якынлаштык дигән сүз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Раҗәб ае башка айлардан, Коръән кеше сүзеннән өстен булган кебек, аерылып тора. Шәгъбан аеның өстенлеге минем башка илчеләрдән өстенрәк торуыма тиң. Ә Рамазан аеның өстенлеге – Аллаһының үз мәхлүкъларыннан өстен булуы кебек үк».

## Раҗәб ае – ярлыкау һәм мәрхәмәткә ирешү ае ул

Раҗәб «Әр-Руҗүб» сүзеннән барлыкка килгән. «Әр-Руҗүб» – «бөекләү, олылау» мәгънәсенә ия. Сүзнең тамыры «тәраҗиб» сүзенә барып тоташа, мәгънәсе – «ихтирамхөрмәт».

Раҗәб ае һиҗри буенча мөселман ай календаренең җиденче ае, ул харам айлар рәтенә керә. Әбү Бәкрат радыяллаһу ганһедән риваять кылына: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бер ел уникe айдан гыйбарәт, шуларның дүртесе – харам айлары, ә аларның өчесе рәттән килә: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам, ә «раҗәб мүзарә» – җөмәдәл-ахыр һәм шәгъбан арасында» (Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Ни өчен хәдистә раҗәб ае «раҗәб мүзарә» дип аталган? Бу Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселендәге бер Мүзарә исемле кешенең исеме белән бәйле. Шушы кешенең кавеме раҗәб аеның вакытын күчерми торган була, башка гарәп кавемнәре, сугышны туктатып тормас өчен, раҗәб аен кичектереп тора торган булалар.

Раҗәб аеның харам айлар рәтенә керүе хакында Изге Коръәндә ачык дәлил бар:

***«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхул-Мәхфүздә] – унике. Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйльдән [галәйһимуссәлам] калган] хак дин. [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез».***

«Әт-Тәүбә», 9:36

Харам айлар дип аталган вакыт аралыгында, дошман явызлык күрсәтмәсә, сугыш алып бару тыела. Үз-үзеңне якларга гына рөхсәт ителә. Югарыда китерелгән аятьтә бу айларда гөнаһлардан тыелуга аерым басым ясала, чөнки гөнаһның авырлыгы арта төшә, ягъни кешенең үзүзенә салган золымының куәте, зурлыгы арта. Шулай ук изге гамәлләрнең савабы да бермә-бер зурая.

## Раҗәб ае нинди вакыйгаларга бай?

Беренчедән, иң зур вакыйгаларның берсе – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе хәзрәти Габдулла һәм әнисе хәзрәти Әминә бу айда никахлашып кавыша. Раҗәб аеның беренче җомгасы төнен зурлап «Рәгаиб кичәсе» дип йөртәләр. Бу төндә кылынган догалар кабул ителә, гөнаһлар кичерелә.

Икенчедән, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдәге Әл-Харам мәчетеннән Кодес (Иерусалим) җирендәге Әл-Әкъса мәчетенә күчеш ясый һәм Аллаһы янына күтәрелә. Бу вакыйга «Әл-Исра вәл Мигъраҗ» дип атала. Ул раҗәб аеның 27 нче төне дип исәпләнә. Мигъраҗ вакыйгасы – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы тарафыннан бүләк ителгән могҗизаларның берсе. Нәкъ менә Мигъраҗ вакытында Галәмнәрнең Раббысы Үзенең колларына биш вакыт намазны фарыз итеп йөкли. Бу хакта бер риваятьтә Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дигән: «Мигъраҗ төнендә Аллаһының Расүленә илле тапкыр намаз укырга йөкләнелде. Соңыннан аңа: «Әй Мөхәммәд! Шиксез, Безнең сүзебез үзгәрмәс. Синең өммәтеңә йөкләнгән биш тапкыр кылыначак намаз савабы – илле тапкыр укылган намазга тиң булыр», – дип әйтелде (Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан). Икенче бер хәдистә шулай ук әлеге вакыйганың фазыйләтләре ассызыклана: «Мигъраҗ вакытында, Аллаһының рәхмәте буларак, өч нәрсә бүләк ителде: биш вакыт намаз, «Әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы аятьләре һәм күп илаһларга табынучы булмаганнарга гафу кылыну мөмкинлегенең барлыгы» (Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Аллаһының Расүле үзенә кадәр җиргә хакыйкатьне җиткерүчеләр булып җибәрелгән Ибраһим, Муса, Гайсә, Идрис, Йосыф галәйһимуссәлам кебек пәйгамбәрләр белән күрешә. Мигъраҗ вакыйгасы Коръәндә болай дип сурәтләнә:

***«Ул Раббысының иң бөек аятьләреннән иң әһәмиятле бер өлешен [Мигъраҗ кичәсендә] күрде».***

«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:18

Раҗәб аенда ураза тотарга ният кылсак, хәерле булыр. Билгеле ки, ураза тоту – Аллаһы һәм Аның колы арасында гына кала торган гыйбадәт төре. Нәкъ тә шуның өчен савабын да Аллаһы Тәгалә күпме бирергә теләсә, шуның кадәр билгелиячәк.

Бер хәдисендә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раҗәб аенда ураза тотыгыз, чөнки бу айда ураза тоту Аллаһы тарафыннан аерым бер тәүбә буларак кабул ителә», – дип әйткән. Әгәр дә тулы бер ай ураза тоту мөмкинлеге юк икән, мәсәлән, кешенең сәламәтлегенә зыян килә яисә эше буенча мәшәкатьләре туа, бу очракта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм айның беренче, унбишенче һәм соңгы көннәрендә ураза тотарга киңәш иткән. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Исегездә тотыгыз: раҗәб – Аллаһы Тәгаләнең ае, бу айда берәрегез бер көн генә булса да ураза тотса, Аллаһы аннан разый булыр,» – дип хәбәр иткән.

Шулай ук Әбү Давыдтан китерелә торган сахих хәдистә болай дип әйтелгән: «…харам айларда ураза тот һәм авыз ач, харам айларда ураза тот һәм авыз ач, харам айларда ураза тот һәм авыз ач…»

Күргәнегезчә, Аллаһының Расүле бер үк гыйбарәне өч тапкыр рәттән кабатлый. Бу – әлеге айларда ураза тотуның никадәр әһәмиятле һәм саваплы булуына ныклы дәлил, мөселман өммәтенә катгый киңәш.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әлхәмдүлилләһ, без янәдән, инде менә гомеребездә ничәнче кат Рамазан аена якынлашабыз. Иншә-Аллаһ, без исән-имин аңа бер халәттә кереп, икенче халәттә чыгарбыз. Хәзер без юлыбызның беренче баскычында – раҗәб аенда басып торабыз. Рамазан аен күңелебезгә бөтен фазыйләтләре белән кунакка кертергә телибез икән, бүгеннән үк әзерлек эшләрен алып барыйк: ураза тотыйк һәм авыз ачыйк, вак-төяк ызгыш-талашлардан, низаглардан тыелыйк, көнебезне Изге Коръән сүрәләрен уку белән бизик, гөнаһлардан ерак торып, игелекле гамәлләрне тагын да арттырыйк.

■ **Ирек хәзрәт НУРИЕВ,**
«Менделеев» районы имаммөхтәсибе

# Каюм Насыйриның тууына 196 ел тулды

*14нче февральдә, татар мәгърифәтчесе, тел галиме, язучы, тарихчы, этнограф Каюм Насыйриның тууына 196 ел тулды. Ул элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы мулла гаиләсендә дөньяга килә. Фәнни-популяр әсәрләр, беренче татар календарьлары авторы К.Насыйри төбәк, татар халкы тарихын, фольклорын һәм этнографик мирасын өйрәнүгә зур әһәмият бирә. Ул гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләрен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Каюм Насыйриның тормыш юлы белән тагын да ныграк танышу өчен, «Сайланма әсәрләр» китабыннан өзек тәкъдим итәбез.*



Каюм Насыйриның тулы исеме — Габделкаюм бине Габденнасыйр әш-Шырдани әр-Рәззакый әл-Болгари…

Милләтебез тарихы бик катлаулы дисәң, «калыпланган, тапталган сүз бит инде бу», – дип әйтүчеләр булыр. Әмма, нишлисең, тарихыбыз – чыннан да үтә катлаулы, гаять каршылыклы, ифрат четерекле. Мәгълүм ки, катлаулы тарих сәхнәсенең геройлары да гади булмый. Каюм Насыйри – моның ачык бер мисалы. Бер яктан, ул каләмдәшләре белән артык аралашмаган, иҗтимагый тормыш эчендә кайнамаган кебек күренә, дөресрәге, үзен милләт эчендә аерымрак, махсусрак урында торуын сизеп-тоеп, белеп яши. «Милләтебез халкын «татар» тәсмия кылсам — яратмадылар, «татар теле» дисәм — яратмадылар», – дип гомумиләштереп, башкаларга үпкә белдерүе моны артыгы белән раслый. Башка әсәрендә «татар» кәлимәсен үз итмәүчеләрне «әрбабе гыйнад» (үҗәтләр төркеме) дип атый… Чыннан да, бу сүзләре, этноним хакындагы расламалары ул заман өчен сәер яңгырагандыр. Хәер, язучыны аңлап та була. Духовное училищеда һәм семинариядә «учитель татарского языка»… булып эшләве, теләсәң-теләмәсәң дә, Насыйри-Болгарины да шул эзгә төшерә.

## Милли әдәбиятны саклау вазифасы

Икенче яктан, үзеннән сон килгән әдипләргә караганда, Габделкаюм Габденнасыйр углы борынгыдан килгән милли әдәби традициябезне өзәргә уйламый да, киресенчә, аны мөмкин кадәр күләмлерәк бирергә тырыша. «Кырык вәзир», мәшһүр «Әбугалисина»сы, үзе бер хәзинә тәшкил иткән «Фәвакиһел җөләса», «Җәваһирел хикаят», «Мәҗмәгыль әхбар» һ.б. — болар барысы да какшамас дәвамчанлыкны күрсәтә. Яшьләр соңыннан тибәреп аударачак мәңге искермәс әдәбиятыбызны ничек булса да аякта торырлык итеп саклауны үзенең вазифасы дип белә. Бу җәһәттән Насыйри Фатих Халидине хәтерләтә (аның «Мең дә бер кичәсе» белән «Мең дә бер сәхәр»ен генә алыйк).

Гомумән, олпат галим Мәсгуд Гайнетдин бик дөрес язганча, Насыйри XIX йөзнең урталарында әдәбиятыбызда шәйләнә башлаган бушлыкны тутыра, аның йөз суын түктерми…

Олуг язучыбыз Мөхәммәдгаяз Исхакый «Ике йөз елдан сон инкыйраз»ында баш герой Җәгъфәрнең хәтерендә бер-ике тарихи исемне генә тергезә: Үзбәк хан, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри. Гомумән, мөселман укымышлылары Насыйри иҗатының гаять зур әһәмиятен һәр заман аңлаганнар, гади халык та ул китапларында сурәтләгән урта гасыр мөселман мәшһүрләрен дә белгән, белә, беләчәк…

> *Телебезнең аңлатмалы сүзлеген төзү һәм, гомумән, телебезне камилләштерү Насыйриның тагын бер бәһасез казанышы».*

Моңа энциклопедик белемлелек димичә ни дисең?! Насыйри халыкны (яшьләрне) тәрбияләү белән аны тиешенчә агарту эшләрен бергә алып барган. «Календар»енда милләттәшләренә файда китерердәй, аларны белем белән агартырдай хәбәрләр, танылган шәхесләр турында мәгълүмат биреп барган.

Тарих, бигрәк тә Тау ягы авыллары тарихы белән кызыксыну, легендар мәгълүматлар, риваятьләр туплау (алар «Сайланма әсәрләр»нең өченче томын тәшкил итә) мәгърифәтчене гыйлемсөяр, фән әрбабы итеп таныта. Тарихта вак детальләренә кадәр чокчыну, хакыйкатьне белергә омтылу Насыйрига аеруча хас. Ул Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария»сен дә читкә какмый, аның (биредә ул Мәрҗани белән каршылыкка керә) һәрхәлдә игътибарга лаек булуын таный, гомумиләштереп әйтсәк, тарихыбызны теге яки бу яктан яктырткан һәрбер (!) әсәргә мөрәҗәгать итү принцибын эзлекле яклый. Нәкъ соңыннан Риза казый да борынгы кулъязма чыганакларга (аларның ни дәрәҗәдә чынбарлыкны чагылдыруы башка нәрсә) бик игътибарлы мөнәсәбәт күрсәткән шикелле.

## Каюм Насыйри – үрнәк зат

Дүрттомлыкның (Сайланма әсәрләр, 4 томда (ред.)) беренче томына кергән «Татар укымышлылары» һәм «Көнчыгыш укымышлылары» исемле бүлекләре Каюм бабаның башкаларга олы хөрмәт белән каравының тагын бер үрнәге. Ишнияз бине Ширнияз, Габдерәхим Утыз-Имәни Әл-Болгари, Сәгыйд бине Әхмәд әш-Шырдани, Әл-Фараби Ибне Сина турындагы хәбәрләре бәхәссез әһәмияткә ия. Казан байларын да калдырмый Насыйри. Алар турында язып, болай ди: «Кеше хакын хакладылар, кеше хакын алып китмәделәр. Үзләре сыеп торырлык йортлары бар иде. Һавага чыгарып, биек биек бина кыйлмадылар… Бирәчәкләре юк иде… Бер тиененә чаклы малларының зәкавәтен (зәкятен – Р.К.) чыгардылар. Зәкавәт вакытында капкаларында бишәр йөз, меңәр кеше булыр иде…» Күренә ки, Насыйри каләменә юмарт, кешелекле байларны алган, алар мисалында башкаларга гыйбрәт бирергә уйлаган.

Гомумән, Насыйри әсәрләрендә гыйбрәт, әҗер-савап һәм җәза төшенчәләре бик тирән, бик тәфсилле аңлатыла, «Сайланма әсәрләр»нең өч томын төзүче Мәсгуд ага Гайнетдин раслаганча, ул «киң катлау демократик укучы өчен дини әдәбият материалларын эшкәртү эшенә алына». Чыннан да, К.Насыйри (бигрәк тә «Мәҗмәгыль әхбар»да) аңлы рәвештә әхлак һәм әдәпнең кагыйдәләрен кабат-кабат укымышлы милләттәшләренең исенә төшерә, җәмгыятьтә ул заманда ук күренә башлаган әхлакый эрозия, битарафлык, мораль җепшеклек очракларын күзәтеп ачына, эче поша. Әдәбият коралы белән милләтнең әхлагын саклап калу, аның киләчәгә хакына каләм көченнән мөмкин кадәр файдалану өчен җан ата. Шунысы мөһим: моны эшләгәндә, ул коры үгетнәсыйхәт юлыннан баруның бик үк уңышлы булмавын аңлап, мәсьәләне хәл итү ысулларыннан нәкъ менә гыйбрәт күрсәтүне иң мәслихәте итеп күрә. «Гыйлем өйрәнү – дин куәте өчендер, түгел мал җыю» принцибы аның гомерлек юлдашы була.


Каюм Насыйри әсәрләренең иң төп үзенчәлекләреннән берсе (бәлки, иң калкып торганы) — милләтпәрвәрлек, ватандарлык һәм, кабатлап әйтик, сәламәт консерватизм. Дүрттомлыкка кергән әсәрләрдә бу сыйфат аермачык күренә һәм бүгенге көндә үз милләтен сөйгән, аның тәрәккый юлларын эзләгән затлар өчен өлге булып кала бирә.

■ **Рәшид КАДЫЙРОВ,**
тарих фәннәре кандидаты
«Сайланма әсәрләр» китабыннан

# Намазга өйрәнәбез

***Намаз – мөселманның бу тормышта аңа Аллаһының биргән барлык нигъмәтләре өчен илтифатын, хөрмәтен күрсәткән гамәле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ахирәттә иң беренче булып намаз уку-укымау турында соралачак», – дип әйткән.***

***Укучыларыбызны бөек бу олуг гыйбадәтне башкару тәртибе белән таныштыра башларга булдык. Иртәнге намазның 2 рәкәгать сөннәтен уку тәртибен карап үтик.***



## 1нче рәкәгать

Кыйблага карап, аяк араларын 4 бармак киңлеге калдырып басабыз, әмма шул киңлектән арттыру киңәш ителми.

Аннан ният әйтелә:

**«Аллаһы ризалыгы өчен, иртәнге намазның 2 рәкәгать сөннәтен укырга ният кылдым, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, халисан лилләһи Тәгалә»** (Ният күңелдә булырга тиеш. Күңелдәге нияткә игътибарыбыз куәтлерәк булсын өчен, тел белән әйтү рөхсәт ителә. Күңелдәге ният булмыйча укылган намаз дөрес булмый).

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән кереш тәкбире әйтелә. (Ирләргә уч төпләрен кыйблага каратып, баш бармакларының очы колак йомшагына тиярлек итеп, кулларын күтәрергә кирәк). Ирләр уң кулны сул кул өстенә куеп, баш һәм чәнчә бармаклар белән сул кулны беләзектән тотып, кендектән бераз түбәнрәк итеп куялар. Болай басып тору кыям дип атала.

Кыямда басып торганда **«Сәнә»** догасын укыйбыз:

**Сүбехәәнәкәл-лааһуммә вә бихәмдикә вә тәбәракәс-мукә вә тәгааләә җәддукә вә ләә иләәһә гайрук.**

Аннан соң **«Фатиха»** сүрәсе укыла:

**Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмду лилләәһи раббил гааләмиин. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики йәүмиддиин. Иййәәкә нәгъбуду вә иййәәкә нәстәгыйн. Иһдинәс-сыйраатал мустәкыйм. Сыйраатал-ләҙиинә әнгамтә галәйһим. Гайрил мәгъдууби галәйһим үәләәд-дааалиин** («Әәмин» эчтән генә әйтелә).

**«Фатиха»** сүрәсеннән соң Коръәннән берәр сүрә укыйбыз, мәсәлән **«Кәүсәр»** сүрәсен:

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.**

**Иннәә әгътайнәәкәл кәүсәр, фәсалли лирраббикә үәнхәр, иннә шәәни-әкә һүәл әбтәр.**

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән рөкүгъка иеләбез (билдән бөгеләбез).

Иелгән килеш:

**«Сүбехәәнә Раббийәл-газыйм»,** – дип 3 тапкыр әйтелә.

Мәгънәсе: «Олуг Раббымны пакь дип таныйм».

(Ирләр кулларын бармак араларын ачык калдырып тез башларына куялар һәм аякларын да, аркаларын да туры тоталар).

Турайганда: **«Сәмигаллаһу лимән хәмидәһ»,** – дип әйтелә.

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә Үзен мактаучыларны ишетә».

Турайгач, **«Раббәнә ләкәл хәмде»,** – дип әйтелә.

Мәгънәсе: «Раббыбыз, барча мактаулар Сиңа гына тиешле».

**«Аллаһу әкбәр»,** – дип әйтеп сәҗдәгә китәбез.

(Җиргә элек тез башлары, аннары кулларның учлары, аннары маңгай һәм борын тидерелә).

Сәҗдәдә баш ике кулның арасында була, аяклар җирдән аерылмыйлар, күзләр борын очына карыйлар).

Сәҗдәдә: **«Сүбехәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлана.

Мәгънәсе: «Бөек Раббымны пакь дип таныйм».

(Сәҗдәдә ирләрнең терсәкләре җиргә дә, кабыргаларга да тидерелми. Аяк бармаклары кыйбла тарафына юнәлтелә).

Сәҗдә тәсбихе әйткәннән соң, **«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән маңгайны җирдән аерып, тез өстендә утырып торабыз. Куллар тез өстенә куела, күзләр тез башларына карый.

(Ирләр сул аякларына утыра, уң аякның бармаклары бөгелеп, кыйблага юнәлтелгән рәвештә бастырылып куела).

**«Аллаһу әкбәр»,** – дип икенче сәҗдә кылына:

**«Сүбехәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлана.

Мәгънәсе: «Бөек Раббымны пакь дип таныйм».

**«Аллаһу әкбәр»,** – дип икенче рәкәгатькә торабыз. Кулларны кендек астында баглап куябыз.

## 2 нче рәкәгать

Аягүрә баскан килеш, башта **«Бисмилләһ», «Фатиха»** сүрәсе укыла:

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмду лилләәһи раббил гааләмиин. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики йәүмиддиин. Иййәәкә нәгъбуду вә иййәәкә нәстәгыйн. Иһдинәс-сыйраатал мустәкыйм. Сыйраатал-ләҙиинә әнгамтә галәйһим. Гайрил мәгъдууби галәйһим үәләәд-дааалиин** («Әәмин» эчтән генә әйтелә).

«Фатиха» сүрәсеннән соң Коръәннән берәр сүрә укыйбыз, мәсәлән «Ихлас» сүрәсен:

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль һү-үәл-лааһу әхәде. Әллааһүс-самәде. Ләм йәлиде вә ләм йүләде. Вә ләм йәкул ләһүү куфүүән әхәде.**

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән рөкүгъ кылына.

Рөкүгътә: **«Сүбехәәнә Раббийәл-газыйм»,** – дип 3 тапкыр әйтелә.

Турайганда: **«Сәмигаллаһу лимән хәмидәһ»,** – дип әйтелә.

Турайгач, **«Раббәнә ләкәл хәмде»,** – дип әйтелә.

**«Аллаһу әкбәр»,** – дип әйтеп сәҗдәгә китәбез:

**«Сүбехәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлыйбыз.

**«Аллаһу әкбәр»,** – дип сәҗдәләр арасында утырып торабыз.

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән икенче сәҗдә кылына:

**«Сүбехәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлана.

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән кагъдәгә утырабыз.

Куллар тез өстенә куела, күзләр тез башларына карый. Ирләр сул аяк табанына утыра, уң аякның табаны бармаклары бөгелеп, кыйблага юнәлтелгән рәвештә бастырылып куела.

Утырган килеш иң элек **«Тәшәһһүд»** укыйбыз:

**Әт-тәхиййәәту лилләәһи вәссаләүәәту вәт-таййибәәт. Әссәләәму галәйкә әййүһән-нәбиййү вә рахмәтул-лааһи вә бәракәәтүһ. Әс-сәләәму гәләйнәә вә галәә гибәәдил-ләәһиссаалихиин. Әшһәду әл-ләә иләәһә илләл-лааһу. Вә әшһәду әннә Мухәммәдән габдүһүү вә расүлүһ.**

Аннан соң «Салават» догасын укыйбыз:

**Аллаһуммә салли галәә Мухәммәдин вә галәә әәли Мухәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мухәммәдин вә галәә әәли Мухәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид.**

Аннан соң **«Раббәнә»** догасы укыла:

**Раббәнәә әәтинә фид-дунйәә хәсәнәтән, вә фил-әәхыйрати хәсәнәтән вә кыйнәә гәҙәәбән-нәәр.**

Башны уң якка борып (бу вакытта күз уң иңбашына карый), **«Әссәләәму галәйкум вә рахмәтуллааһ»**, – дип уң якка сәлам бирәбез.

Башны сул якка борып (бу вакытта күз сул иңбашына карый), **«Әссәләәму галәйкум вә рахмәтуллааһ»**, – дип сул якка сәлам бирәбез.

Сәламне гамәлләребезне язучы фәрештәләргә һәм тирә ягыбыздагы мөселманнарга ниятләп бирергә кирәк.

**Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ»**, – дип әйтеп, сәлам догасы укыла:

**Аллаһуммә әнтәс-сәләәму вә минкәс-сәләәму тәбәрактә йә ҙәл җәләәли вәл икрам.**

Моннан соң учларыбыз белән битне сыпырып куябыз. Ике рәкәгать намаз моның белән тәмам була.

Шул рәвешле иртәнге намазның ике рәкәгать сөннәте һәм фарызы, өйлә, ахшам, ястү намазларының ике рәкәгать сөннәте укыла. Бу вакытта бары тик укылачак намазның нияте генә үзгәрә. Ниятттә, нинди намаз укырга бассак, шул намазның исемен әйтеп, намазга керешергә кирәк булачак.

Киләсе саннарда да сезне шушы олуг гыйбадәт белән таныштыруны дәвам итәрбез.

■ **«Намаз уку тәртибе»** китабыннан

# «Хафизлар – Коръәннең былбыллары»



***Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сезнең иң хәерлегез Коръәнне өйрәнеп, аны башкаларга өйрәтүче», – дип әйткән.***

Коръәнне тулысынча ятлап чыккан кешене «хафиз» дип атыйлар. Әлеге исемгә лаек булу – бик мактаулы эш, чөнки бу кешеләр Коръәнне тулысы белән үзләренең хәтерләрендә саклый.

## «Хәтем»: Коръәнне башыннан ахырына кадәр укып чыгу

Изге Китабыбызны тулысынча укып чыгу «хәтем» дип атала. Һәр ел саен Рамазан аеның төннәрендә, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән Җәбраил галәйһиссәлам бер-берсенә чиратлашып, моңа кадәр иңгән аятьләрне укый торган иде. Расүлебез укыганда – фәрештә, ә фәрештә укыганда Расүлебез тыңлаган. Бу рәвешле чиратлашып уку рәвеше «мукабәлә» дип атала. Болай уку «мукабәлә» гадәтенең барлыкка килүенә һәм Коръәни Кәримнең үзгәрмичә безнең көннәргә килеп җитүенә сәбәпче булган.

Бу гадәткә тугрылык саклап, Рамазан аенда Коръәнне хәтем кылырга, ягъни башыннан азагына кадәр укып чыгарга тырышырга кирәк.


## «Хат» сәнгате

Коръәнне матур итеп язу өчен, сәнгатьнең «хат» (каллиграфия) дип аталган билгеле бер төре бар. Әлеге сәнгать белән шөгыльләнүче кешене «хаттат» дип атыйлар.

Бу рәвешле язар өчен, махсус материаллар һәм каләмнәр бар. Шулай ук махсус тәртипләр һәм язуның төрләре билгеле. Яхшы «хаттат» булыр өчен, үз эшенең остасы булган белгечтән дәресләр алу кирәк. Матур итеп язылган Коръәни Кәримгә сокланмыйча мөмкин түгел. Андый Коръән матур шрифт белән төсле битләргә төшерелә.


Мөселман мәдәниятенең байлыгы – ул матур язылган Коръән белән беррәттән, «хаттат» тарафыннан язылган картиналар да. Гадәттә, аларда Аллаһы, Мөхәммәд дип язылган була. Күпләребезнең йортлары, мәчет-мәдрәсәләребез мондый картиналар белән бизәлгән. «Хат»сәнгате белән әзерләнгән дөньядагы иң матур картиналар мөселманнарда саклана. Шуның өчен бүгенге көндә әйтелә торган: «Коръән Мәккәдә иңгән, Мисырда укылган, Стамбулда язылган», – дигән сүзләр бөтен дөньяга таралган. Төрле стильләр белән язылган Коръәннәр бар. Безнең кулларда булган Коръән Госман хафизның «хат»ы белән язылган.

■ Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде



# Әюб галәйһиссәлам кыйссасы

*Әюб галәйһиссәлам чын диндар кеше сыйфатларын һәм хакыйкый сабырлык үрнәкләрен үзендә гәүдәләндергән, исәпсез-хисапсыз байлыкларга ия булган. Аңа караган җирләрнең – чиге, ә көтүлекләрнең саны булмаган. Әмма иң кадерле байлыгы күпсанлы балалары булган.*



Рәхимәнең булган акчасына кирәкле азык-төлек сатып алуы хакында шәһәр халкына да билгеле булган. Аның турында гайбәт тарата башлаганнар. Әлеге хәбәрләр Әюб галәйһиссәламгә дә барып җиткән һәм ул болай дип әйткән:

– Әгәр мин бу авырудан терелсәм, мин сине җәзалаячакмын, йөз таяк бирәчәкмен.

Хәбәр ителә ки: Әюб галәйһиссәлам әлеге авыру белән җиде ел дәвамында җәфа чиккән, икенче бер риваять буенча ул унҗиде ел авырган. Әмма шушы вакыт эчендә ул бер тапкыр да үзенең чиреннән зарланмаган. Ул сабырлык күрсәткән һәм Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен белдергән.

Бервакыт Әюб галәйһиссәлам янына, хәлен белергә дип, өч кеше килгән. Һәм сөйләшү барышында аларның берсе болай дип әйткән:

– Әюб авыр бәлагә юлыкты. Озак вакыт үтсә дә, аңа Аллаһының рәхмәте ирешмәде инде. Аллаһы Тәгалә аннан йөз чөергәндер.

Әлеге сүзләр Әюб галәйһиссәламне бик тә борчуга салган һәм күңелен төшергән: «Шулкадәр үк көчле афәтме бу? Дин кардәшләрем Аллаһы миннән йөзен чөерде дип уйлый башлаганнар», – дип уйланган. Һәм шул чагында ул Аллаһы Тәгаләгә дога белән мөрәҗәгать иткән. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

***«[Расүлем!] Әюб галәйһиссәламне дә искә ал! Менә ул, [каты чир белән авырып, еллар буена сабыр иткәннән соң, намазга тора алырлык та көч таба алмагач], Раббысына [дога белән] эндәште: «Һичшиксез, миңа бер зарар кагылды. Син исә мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесесең».***

***Без [догасын кабул итеп] аңа җавап бирдек һәм аңа килгән зарарны китәрдек. Хозурыбыздан бер рәхмәт һәм гыйбадәт кылучыларга бер үгет булсын дип, [үлгән балаларын терелтеп, картаеп беткән хатынын яшәртеп] аңа гаиләсен һәм [шулкадәр үк бала, онык биреп] янында булган кадәрен [кабат] биргән идек».***

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:83-84

Әюб галәйһиссәламгә Аллаһының әмере килгән:

***«Аягың белән [җиргә] тип! [Ул әмеребезне үтәгәч, чишмә бәреп чыкты]. Бу салкын су – коеныр һәм эчәр өчен» [дидек].***

«Сад», 38:42

Әюб галәйһиссәлам Аллаһының әмерен үтәгән. Ул аягы белән типкән һәм җирдән үтә күренә торган су бәреп чыккан. Ул эчәр өчен – салкын, әмма, бер үк вакытта, юыну өчен җылы булган.

Әлеге суны эчеп, ул эчтәге авыруларыннан, аның белән юынып, ул тире авыруларыннан котылган һәм яңадан саулыкка ирешкән. Аңа элекке көче һәм яшьлеге кире кайткан.

Җәбраил галәйһиссәлам аңа чиста һәм кыйммәтле кием кидергән. Аллаһы Тәгалә аңа элекке байлыгын кире кайтарган һәм аны күпләгән балалар белән бүләкләгән (бер риваятьтә Аллаһы аның үлгән балаларын да терелтә, дип килә).

Шулай итеп, барлык бәлаләргә һәм авырлыкларга да карамастан, Әюб галәйһиссәлам Аллаһыга өметен җуймаган, сабыр булган һәм әлеге сынауларны уңышлы үткән, һәм, шуның өчен, аңа байлыгы һәм балалары кайтарылган.

Бер риваятьтә болай дип әйтелгән:

Әюб галәйһиссәлам элекке яшьлек кыяфәтенә кайткач, хатыны Рәхимә бу хакта әле белмәгән. Гадәттәгечә, ул иртән азык-төлек алырга дип шәһәргә чыгып киткән. Күпмедер вакыт узгач, Рәхимә кабаттан әйләнеп кайткан, әмма ирен өйдә очратмаган, һәм күз яшьләре белән болай дип елый башлаган: «Минем авыру ирем белән ни булды? Аны ерткыч җанвар өстерәп алып китте микәнни?» Шул мизгелдә Әюб галәйһиссәлам аннан сораган:

– Ий, хатын, син кемне эзлисең?

– Минем авыру ирем бар иде. Мин аны югалттым.

– Аның исеме ничек?

– Әюб.

– Ә ул нинди кыяфәттә иде?

– Сәламәт булганда ул бик тә сиңа охшаган иде.

– Ий Рәхимә! Әюб мин булам инде ул.

Алар кочаклашканнар һәм Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен белдергәннәр. Бергәләп шәһәргә төшкәч, аларның өйләре яңарганын, балалары кабат терелгәнен, байлыклары һәм көтүлекләре кире кайтарылганын күргәннәр.

Ә «Рәхимәгә йөз таяк» турындагы ант белән нишләргә соң? Әюб галәйһиссәлам хатынына яла ягулары хакында аңлаган. Һәм Аллаһы Тәгалә Әюб галәйһиссәламгә кайгыда һәм шатлыкта да тугрылыклы булган тормыш иптәше Рәхимә өчен җәзаны киметә торган юлны күрсәткән. Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

***«Кулың белән [йөз чыбыклы] бер бәйләм ал да шуның белән [хатыныңа] сук һәм антыңны бозма» [дип вәхи иттек]. Һичшиксез, Без аны сабыр итүче буларак [белгән хәлдә] таптык. [Ул] Нинди күркәм бер кол иде! Һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде».***

«Сад», 38:44

Ул йөз чыбыкны бер бәйләмгә җыйган һәм җиңелчә генә итеп бер тапкыр әлеге бәйләм белән хатынына кагылып киткән. Шулай итеп үзенең антын үтәгән. Авырлыклар, сынаулар чоры артта калган.

### Елау сәбәбе

Әюб галәйһиссәлам яңадан үзенең мал-мөлкәтен һәм балаларын кире кайтаруга ирешкән төндә, ул таң алдыннан уянган һәм елаган:

– Һәр төнне мин таң алдыннан: «Ий безнең хастабыз! Син ничек?» – дип сораган илаһи тавышны ишеттем. Әмма әлеге тавыш башка ишетелми, шуңа күрә елыйм.

Байлык һәм ярлылык, саулык һәм авыру кебек сынауларга дучар ителгән Әюб галәйһиссәлам барлык авырлыкларны олуг сабырлык белән узган, бар кешелек өчен тайпылышсыз чыдамлык үрнәгенә әверелгән.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

***«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер!»***

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155

■ **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
Татарстан Республикасы
мөфтие



(Дәвамы. Башы алдагы санда)

# Хабибрахман Шакир: меңләгән күлләр иленә сикәлтәле юл



Хабибрахман Шакир Әл-Болгари (үзәктә). Пешавар

**Пешавардагы тормыш битләреннән...**

1930 елда Хабибрахман Шакир Әфганстаннан Пешавар (ул вакытта Британия колониясе составындагы Һиндстанга кергән) шәһәренә күчә. Ә хәзер ул, Пакыстан-Әфганстан чикләрендә урнашкан, Пакыстанның чик буендагы шәһәре булып тора.

Көнчыгыш Төркистаннан булган Мөхәммәд Гали Рахмәтуллин (Мөхәммәд Гали Рахмәтулла улы) ярдәме белән, безгә Хабибрахман Шакирның Пешавардагы тормышыннан кызыклы фактлар билгеле булды. Шунысы ук кызыклы: алар әлеге зур шәрыкъ шәһәрендә очрашып, шәхсән таныша алганнар. Ул вакытларда Пешаварда элеккеге Рәсәй империясенең совет хакимияте тарафыннан җәберләүләргә дучар ителгән бик күп мөселман качкыннары яшәгән. Күчеп килүчеләрнең күпчелеге Урта Азиядән, шул исәптән, Көнчыгыш Төркистаннан булган.

Мөхәммәд Гали Рахмәтуллин сәүдә эшләре белән Кашгар (Көнчыгыш Төркистан) шәһәреннән Пешаварга килә һәм җирле халык тарафыннан бер мәҗлескә чакырыла. Монда ул очраклы рәвештә «Яңа Милли юл» («Новый национальный путь») журналына тап була.


Бу журнал 1920-30 елларда Гаяз Исхакый тарафыннан, Берлинда нәшер ителә һәм татар иммиграциясенең периодик рәвештә чыгып килә торган төп басмасы була. Аның: «Бу басманы кем яздыртып ала?» – дигән соравына: «Мәүләви Хабибрахман Әл-Болгари», – дип җавап биргәннәр. «Мәүләви» сүзе, гарәпчәдән «хаким», «тәрбия кылучы», «хуҗа», дип тәрҗемә кылына. Урта Азия, Иран, Әфганстан, Пакыстан һәм Һиндстан мөселманнары арасында бу сүз хөрмәтле дин галименә, шәригать хөкемнәре белгеченә эндәшкәндә кулланыла. Мөхәммәд Гали Рахмәтуллинның Хабибрахман Шакир белән танышуы шул рәвешле булган.

Хабибрахман Шакир Пешаварда качкыннарны туплау буенча актив эшчәнлек алып барган. Аның тырышлыгы белән, «Мәдрәсәт әл-мөһаҗирин» («Мөһаҗирләр мәдрәсәсе») дип исемләнгән, күченеп килүчеләрнең балалары укый торган мәдрәсә барлыкка китерелә. Аннары ул әлеге мәдрәсәдә укыткан, аның имамы булган, мәдрәсәне җиһазландыру һәм финанс яктан тәэмин итү мәсьәләсен кайгырткан.

Мөхәммәд Гали Рахмәтуллин сүзләре буенча, Хабибрахман Шакирның хәлләре мөшкел була. Аңа, мәдрәсәне тәэмин итәр өчен, чыгымнар табу кыен була, чөнки күченеп килүчеләр, балаларын укытыр өчен, үзләренең акчаларын корбан итәргә бик омтылмый. Моннан тыш, Хабибрахман Шакир китаплар язарга да вакыт таба. Ул башка илләргә дә таралган мөселман мөһаҗирләре белән хатлар алышып, тыгыз элемтәдә торган. Шулай ук, Ерак Көнчыгыштагы «Милли Байрак» («Национальное знамя») исемле татар газетасында да басыла торган булган. Ул Пешавардагы һәм Көнчыгыш Төркистандагы мөселманнарның тормышы хакында хәбәр биреп торган һәм төрле юллар белән аларның проблемаларын хәл итәргә тырышкан.

■ **Мөхсин НУРУЛЛА** язмасы, **islam-today.ru** сайтыннан тәрҗемә


(Дәвамы киләсе санда)



«Яңа Милли юл» журналы, Берлин, № 7, 1933 ел, июнь



Финляндия татарлары. Балалар укытучы белән милли курсларда. 1932-1933 еллар, Куопио, Финляндия



# Мәңгелек патшалык

Бер тәкъва иясе Сөләйман галәйһиссәламнең патшалыгын күреп: «Йә Аллаһының Расүле! Аллаһы сиңа шундый зур патшалык биргән», – дип әйткән.

Сөләйман галәйһиссәлам: «Бер кешенең гамәл дәфтәрендәге хәмед-сәна сүзе Сөләйманның патшалыгына караганда яхшырак. Хәмед-сәналәр мәңгелек, ә Сөләйманның патшалыгы кайчан да булса бетәчәк, – дип җавап кайтарган.

**Нәсыйхәт:**

***«Мал һәм ир балалар – дөнья тормышының [вакытлы һәм бик тиз үтә торган] зиннәте. [Мәңге] Бетми торган [тәсбих, мактау, тәүхид һәм тәкбир зикерләре, биш вакыт намаз, ураза, хаҗ һәм зәкят кебек] игелекле гамәлләр исә Раббыңның хозурында савап ягыннан да яхшырак, өмет баглау ягыннан да лаеклырак...»***

«Кәһф / Тау куышы», 18:46

Аллаһыны искә алу, ягъни «Аллаһы» сүзләре Сөләйман пәйгамбәр патшалыгына караганда кыйммәтлерәк булгач, Аллаһының бөек Кәламе булган Коръәнне укуның савабы нинди булыр?! Аны укыган өчен, зур савап бирелүендә шик юк.

# Начар исле эт үләксәсенең ак тешләре

Берьюлы Гайсә галәйһиссәлам, үзенең шәкертләре белән юлдан барганда, эт үләксәсенә тап була. Аннан бик начар ис килә иде. Шәкертләр:

– Эт үләксәсенең исе бигрәк начар, – дигәннәр.

Гайсә галәйһиссәлам:

– Аның тешләре бигрәк ак һәм матур, – дип әйткән.

**Нәсыйхәт:**

Әлеге сүзләре белән Гайсә галәйһиссәлам кешенең яхшы якларын гына искә алырга кирәклеген ассызыклый. Хайван үләксәсенә карата булган мөнәсәбәте белән Гайсә галәйһиссәлам мөселман кешесенең кардәшенә нинди мөнәсәбәттә булырга тиешлеген күрсәтә. Һәрбер кешенең яхшы сыйфатлары бар. Мөселман кардәшең турында: «Ул мондый, ул тегенди», – дип әйтү бик җиңел. Алай дип әйткәнче: «Әйе, аның мондый яклары бар, әмма ул юмарт кеше һәм биш вакыт намаз укый», – дип әйтү кирәк. Син хаталанганда яки сөртенгәндә сиңа берәрсе ярдәм кулы сузсын өчен, син дә башкаларга ярдәм кулы суз. Сүриядә бер укытучы тактага нокта куйган да, укучыларыннан: «Тактада нәрсә күрәсез?» – дип сораган.

Барысы да ноктаны күрсәткән. Укытучы укучыларына түбәндәге сүзләрне әйткән: «Сез кечкенә генә кара ноктаны күрдегез, әмма тактаның ак булуына игътибар итмәдегез».

# Нәсыйхәт

Шәех Әбел-Габбас Әл-Җүвәлики рахимәһуллаһи рухи яктан камилләшү һәм гыйлем алу юлына басканчы, капчыклар тегү һәм аларны сату белән шөгыльләнә торган була. Берьюлы ул бер кешегә капчык сатканнан соң акчасын алырга онытa, теге кеше дә түләүне истән чыгара. Намаз вакыты җиткәннән соң, ул намазга баса. Һәм намаз вакытында капчыкны кемгә сатуы турында уйлый башлый. Намазын тәгәлләгәч, үзенең ярдәмчесенә: «Намаз вакытында миңа капчыкны кемгә сатуымны хәтерләмәвем турында уй килде», – дип әйтә.

Ярдәмче аннан:

– Йә остам! Син намаз укыдыңмы әллә акча турында уйладыңмы? – дип сорый.

Ярдәмчесенең сүзләре аңа шулхәтле тәэсир ясый һәм ул капчыкларның берсен киеп, дөнья тормышыннан ваз кичә, әхлакый яктан үзен камилләштерү юлына баса.

**Нәсыйхәт:**

Әйе, кеше, үзен һәм гаиләсен тәэмин итәр өчен, эшләргә тиеш. Әмма истән чыгарырга ярамый: акча һәм байлык – коллану чаралары гына. Кеше аларны файдаланырга тиеш, әмма йөрәгендә аларга карата артык мәхәббәт булуы дөрес түгел, чөнки, әйтелгәнчә: «Кораб бортының тышындагы су – имин йөзүнең сәбәбе, ә кораб эчендәге су – һәлакәткә сәбәп».

**«Рухуль Бәйан»** китабыннан

# Яманлык эзсез югалмас

Бу дөньяда төрле кешеләрнең хәлләренә кызыгырга мөмкин. Берәүләр – бай, икенчеләр – танылган, өченчеләр – дәрәҗәле кеше булып тормыш алып бара. Әмма кешеләрдә иң сокландыра торган сыйфат – ул аларның көчле рухлы, ныклы ихтыярлы, иманлы, кешелекле булулары, чөнки байлык, матурлык, дәрәҗә – вакытлыча. Хәтта алар гомерлек булсалар да, барыбер вакытлыча гына, чөнки бу дөнья нигъмәтләре билгеле бер вакытка гына бирелгән, бу дөньяда без кунак кына. Ә мөнә иманлы, кешелекле булып яшәвебез ике дөнья бәхетенә дә сәбәпче булачак. Андый кешеләргә бик тә авыр, билгеле, чөнки бу тормышта кешелек сыйфатларын саклап калу җиңелләрдән түгел. Бу кешеләр башкаларга карата мәрхәмәтле, Раббыларына шөкерле булулары белән аерылып тора. Аларның уңышлары: бу дөньяга вакытлыча гына килгәннәрен аңлап, һәр хәлдә дә сабырлык күрсәтүдә, Аллаһы биргән гомерләрен яратып, кешеләргә үч сакламыйча яши белүдә.

Кызганычка, еш кына нәкъ шундый кешеләр күпләрдә көнчелек хисләре тудыра. Бер карагaнда, башкалардан артык яклары юк, булдыра алганча тормыш алып бара, тырыша, харамга керми, алар өчен аз булса да, хәләл мал кадерле. Тик кайберәүләр мондый кешеләрнең «абынуын» тели, алай гына да түгел, «тормыш тәгәрмәченә» таяк кыстырырга бер форсат кына көтеп йөри. Әмма яманлык кылып, моны беркем белмәдe, дип уйлаучылар Коръәни Кәримнең әлеге аятен белми ахыры. Раббыбыз: ***«Аллаһы залимнәр кылган нәрсәләрне белмидер, дип уйлама...»,*** – дип әйткән.

«Ибраһим», 14:42

Халкыбызда: «Кырын эш кырык елдан соң да беленә», – дигән мәкаль бар. Әгәр берәү яманлык кылса: кемнеңдер өлешенә керсә, аңа яла якса, намусына тап төшерергә теләсә, аны авыр хәлдә калдырса һ. б. начарлыклар эшләсә, максатыма ирештем, дип җиңел суларга ашыкмасын, чөнки аның яманлыгы эзсез югалмаячак. Раббыбыз Коръәндә:

***«Кем дә кем [дөньяда] зәррә авырлыгы кадәр генә начарлык кылса, аны [Ахирәттә] күрәчәк»,*** – дип әйткән.

«Әз-Зәлзәлә / Җир тетрәү», 99:8

■ **Айсылу ЮЛДАШЕВА**

# Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе



## Тууы

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе якынча 595 елда Мәккә шәһәрендә, Әбү Вәккас Мәлик гаиләсендә дөньяга килгән. Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

## Нәселе

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе Мәккәнең мәшһүр гаиләсендә туган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән дә аны туганлык җепләре бәйләгән. Әйткәнебезчә, аның этисе – Әбү Вәккас, ләкин бу аның куньясе (кушаматы) гына. Аның чын исеме – Мәлик бине Вәһиб бине Габдемәнәф бине Зәһра бине Киләб. Аның шәҗәрәсе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәҗәрәсендәге Киләб нәселенә барып тоташа. Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә бинте Вәһеб чыгышы белән Бәну Зәһра нәселеннән. Шул рәвешле, Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әнисе Әминәнең ике туган абыйсы, ә Пәйгәмбәребезгә әнисе ягыннан абзасы килеп чыга.

Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһедән китерелгән риваятьтә әйтелә: Сәгъд бине Әби Вәккас кергән чагында, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм горурлык белән: «Ул минем әнием ягыннан туганым һәм тагын кайсыгыз Сәгъд кебек абзасы белән горурлана ала?» – дип әйтә торган булган.

## Ислам динен кабул итүе

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе ислам динен 19 яшендә (ә кайбер чыганакларда 17 яшьтә) кабул иткән. Бу – Ислам диненең яңа гына тарала башлаган вакыты, шуңа да динне кабул иткән мөселманнар саны бик аз булган. Шунлыктан, аларны һәр җирдә кирткәләр, авыр сынаулар сагалаган.

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһенең кызы Гайшә, әтисенең сөйләүләре буенча, аның Ислам динен кабул итүе хакында түбәндәгеләрне риваять кылган.

Бервакыт Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе могҗизалы төш күргән. Әйтерсең лә, ул бер караңгы бүлмәдә икән һәм анда бернинди дә яктылык кермәгән. Көтмәгәндә каяндыр бик якты ай нуры барлыкка килгән һәм Сәгъд бине Әби Вәккас шул ай яктылыгына таба атлый башлаган. Шул чагында ул үзеннән алда айга таба баручы кешеләрне күргән. Алар арасында Әбү Бәкер Әс-Сиддыйк, Гали, Зәйд бине Харрис радыяллаһу ганһүмәләр булган. Белүебезчә, хатын-кызлар арасында беренче булып Ислам динен кабул итүче – Хәдичә радыяллаһу ганһә, балалар арасында – Гали, аннан соң, ирекле булган кешеләрдән – Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе, ә коллар арасында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәрбиясендә үскән Зәйд бине Харрис булган. Сәгъд бине Әби Вәккас алардан кая барулары хакында сораштыргач, алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең килүе һәм кешеләрне ислам диненә чакыруы турында әйткәннәр. Алар аны да Ислам динен кабул итәргә һәм үзләре артыннан барырга чакырганнар.

Икенче көнне Сәгъд бине Әби Вәккас Әбү Бәкер радыяллаһу ганһене күргән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аны мөселманнарның яшерен җыела торган урыннарына – Әркамә йортына килергә чакырган. Монда Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән очрашкан һәм Ислам динен кабул иткән.

Сәгъд бине Әби Вәккас ислам динен кабул иткәч, тормышы авырлаша. Бигрәк тә якын туганнары моңа каршы булганнар. Улының ислам динен кабул итүе хакында белгән әнисе аңа бик нык ачуланган. Яраткан улының бу гамәлен нәселләренә хыянәт итү дип санаган һәм ризасызлыгын белдереп болай дип әйткән: «Әгәр дә син яңа динеңне ташламасаң, мин үземә үлгәнче ашау-эчүне харам кылам. Син үкенечкә калып кешеләр алдында хур булырсың». Улы әнисенә: «Әнием, болай эшләмә, мин барыбер үз динемнән ваз кичмәм», – дип әйтсә дә, әнисе үз сүзләрендә нык торган. Берничә көн дәвамында ул бернәрсә дә ашамаган һәм эчмәгән, бик нык хәлсезләнгән. Улы Сәгъд аны күпме юатырга тырышса да, әнисе бу гамәленнән туктамаган, тыңламаган. Улы: «Ий, әнием, сине күпме яратсам да, әмма Аллаһыга һәм Пәйгамбәрем салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә яратуым көчлерәк. Мин үз динемнән беркайчан да баш тартмам», – дип әйткән.

Әнисе улының үз карарында нык торганлыгын аңлап, улына карата йомшарган һәм тамагына ризык каба башлаган.

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе Коръәни Кәримдәге «Локман» сүрәсенең түбәндәге аятьләре нәкъ менә аның очрагына бәйле һәм аның кебекләр хакында иңдерелгән дип әйтә торган булган.

***«Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә. Миңа һәм ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа. Әмма ул икәү синең бернинди гыйлемең булмаган [потлар һәм гаҗиз] нәрсәләрне [күрә торып] Миңа ширек кылуың өчен сине көчли калсалар, аларга итагать итмә. Әмма дөньяда ул икәү белән яхшы күрелгән рәвештә бергә бул. Ләкин син [ата-анаңның юлына түгел, тәүхид һәм ихлас белән] Миңа юнәлгәннәрнең юлына ияр. Соңыннан [барыгызның да] кайтуыгыз Миңа [булачак], Мин исә сезгә ни кылганнарыгызны хәбәр итәчәкмен».***

«Локман», 31:14-15

## Төп сыйфатлары

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе бик юмарт булуы белән аерылып торган. Тапкан барлык малын Аллаһы юлына тоткан. Бервакыт Сәгъд бине Әби Вәккас нык авыртып киткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның хәлен белешергә килгәч, ул болай дип әйткән: «Ий Аллаһының Расүле! Минем бердәнбер кызымнан кала башка балаларым юк, ләкин минем байлыгым шактый күп. Бар байлыгымны да Аллаһы юлына тотарга рөхсәт ит!» Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның бу теләгенә каршы килгән. Шуннан соң Сәгъд бине Әби Вәккас байлыгының яртысын садака буларак тарату мөмкилеге хакында сораган. Аллаһының Расүле моңа да ризалашмаган. Шуннан соң ул байлыгының $^{1}/_{3}$ өлеше хакында сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа болай дип әйткән: «$^{1}/_{3}$ өлеше дә күп әле. Үз варисларыңны ярлылыкта калдырганчы, байлыкта калдыруың хәерлерәк. Син шуны яхшы бел, әгәр син, Аллаһының ризалыгы, өчен үз малыңнан нәрсә булса да тотсаң, хәтта хатыныңа ризык өчен булса да, һичшиксез, син Аллаһыдан бу гамәлең өчен әҗерен алырсың». Ахырда өстәп болай дип тә әйткән: «Аллаһының рәхмәте белән син савыгырсың һәм мөэминнәргә – күп файда, ә Ислам диненә каршы булган дошманнарга зыян салырсың» (Имам ӘбүДавыдхәдисләрҗыентыгыннан).

Шуны да искәртеп үтик, Сәгъд бине Әби Вәккасның бар байлыгы хәләл юл белән, үз тырышлыгы белән табылган. Нәкъ шул сыйфаты аңа җәннәт белән шатландырылучылар рәтенә керергә ярдәм дә иткән. Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре белән утырган вакытта болай дип әйткән: «Җәннәтле кешене күрәсегез килсә, хәзер монда керүчегә карагыз». Барысы да бу бәхетле кешене күрергә теләгәннәр. Шул чагында Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу кергән. Ул чагында әле яшь булган Габдулла бине Гомәр үзеннән әллә ни аерылмаган Сәгъд бине Әби Вәккастан нинди сыйфатлары сәбәпле җәннәт белән шатландырылуы хакында сораган. Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе аңа болай дип җавап биргән: «Мин – гади кеше, үзенчәлекле эшләр дә башкармыйм, ләкин мин һәрвакытта да өч әйберне чисталыкта тотарга тырышам. Болар – минем телем, йөрәгем һәм байлыгым. Мин беркайчан да чит кешеләр хакында начар сүз сөйләмәдем, беркемгә дә явызлык теләмәдем һәм үземнең бар байлыгымны да бары тик хәләл юл белән генә тупладым».

Сәгъд бине Әби Вәккас бозыклыктан, гөнаһлы эшләрдән ерак торган. Яраткан шөгыльләре ук һәм җәя ясау булган. Шуңа да ул оста сугышчы булуы белән дә аерылып торган. Бәдер, Өхед, Хандакъ сугышларында катнашкан. Өхед сугышында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яклаган ун сәхабә арасында булган.

Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр идарә иткән вакытларда хәлифәтне ныгытуда зур хезмәтләр куйган. Рум һәм Иранга каршы гаскәр башлыгы булган. Аның җитәкчелегендә Кадисия сугышында җиңү яуланган.

## Вафаты

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе 674 елда, 83 яшендә вафат булган. Үз васыяте буенча, Сәгъд бине Әби Вәккасны, Бәдер сугышында мөшрикләргә каршы сугышканда кигән йон җөббәсенә (ефәк яки ефәккә охшаган тукымадан тегелгән япма) төреп, Мәдинәдән 10 миль ераклыктагы бер җирлектә җирләгәннәр.

■ Сәхифәне **Лилия ХӘЛӘФЕТДИНОВА** әзерләде

# Кайнар диңгез юлы



*(Повестьтән өзек)*

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

– «Москвич» машинам бар, кая кирәк, шунда алып барам, хәзрәт. Сургут шәһәрендә җәмәгать белән намаз укырлык бер йорт булса да табыйк. Су кудыру каналы җитәкчесе Әнвәр Зәйнуллин белән сөйләшеп карыйк әле, үзебезнең мөселман кешесе, – диде.

Шушы сүзне генә көтеп утырган Таһир, җанланып китте. Ярты сәгатьтән алар Әнвәрнең кабинетында утыралар иде инде. Таһир, мәчет салырга җир бирмиләр дип, проблемасын әйтте. Хуҗа аны илтифат күрсәтеп тыңлады.

– Безнең оешманың элекке урынында «Кызыл почмак» бинасы калды. Барып карыйк әле, мәчет итеп файдаланып торырлык әле ул, – диде.

Өчесе бергә «Кызыл почмак» бинасын карарга бардылар. Кыйблага юнәлгән. Каршысында – урман. Табигать кочагында бит бу! Ишеген ачып керсәләр, электр үткәрелгән, газ белән җылытыла. Таһирнең куанычыннан, сулышы киңәеп китте.

– Рәхмәт сезгә, Әнвәр дус! Вакытлыча файдалану өчен, менә дигән бина бу! – диде.

...Икенче көнне Таһир «Кызыл почмак»ка Рәйсәне алып килде. Башта йортны юып чыгарырга, аннары обойларга кирәк, дигән ният белән икесе эш башладылар. Аларга булышырга иң беренче башкорт хатыны Хәдичә апа килде һәм, җиңен сызганып, эшкә кереште. Әхәт Илялов исемфамилияле җитәкче урындыклар, аның сәркатибе Галия Мәүлиева төргәге белән тукыма китерде. Нефтьчеләр паркындагы «Кызыл почмакта» гыйбадәтханә булачак дигән хәбәр, мөселманнар арасында тиз таралды. Булышырга килүчеләр саны көн саен арта торды. Рәйсә күрше йортта яшәүче Бәхия апаларга кереп, Галия китергән тукымадан пәрдәләр текте. Обойлап, яңа пәрдәләр дә элеп куйгач, «Кызыл почмак» бинасы, чын гыйбадәтханә йортына әйләнде. Таһир хәзрәт гарәп графикасы һәм намаз тәртипләре укыта башлады. Дәрескә йөрүчеләр ун кешедән башланды.

...Сургут җирендә Таһир хәзрәтнең беренче ярдәмчесе Наиф абый:

– Себер җирендә динне син торгызырга тиеш, энем! Монда кеше үлгәндә, җеназа да укылмады. Син дини тәртипләрне беләсең, барысын да җайга салырсың дип ышанам, – диде.

Гыйбадәтханәгә халык төрле сораулар белән килә башлады. Рәйсә көне буе иренең сәркатибе вазифасын башкарды, һәркемнең соравын игътибар белән тыңлап, иренә җиткереп торды.

– Руслар белән татарларның бер зиратта күмелгәнен беләсезме сез? Катнаш була алмый, моны аерырга кирәк, – диде урта яшьләрдәге ир кеше.

Таһир хәзрәт мөселманнар өчен аерым зират булдыру кирәклеген хакимият җитәкчеләренә шул көнне үк җиткерде. Мөселманнар белән христианнар өчен, аерым зират булдырылды. Элекке тәртип буенча кабер казучылар хәзрәттән аракы сорый башладылар.

– Болай ярамый, кардәшләр, ислам динебез буенча мәетне хәрәм эчеп озатмыйлар, сез зур гөнаһ эшлисез, – дип, башта аңлатырга тырышып карады.

Аракы корбанына әйләнгән кешегә мондый сүзләр генә үтмәвен аңлагач, андыйлар белән арасын өзде. Изге эшкә изге күңелле кешеләр табылды. Тәлгат белән Дамир үзләре теләп, зират каравылчылары булып эшкә алындылар.

– Хәзрәт, әйтергә дә оят, дини тәртипләрне белүче булмагач, монда моргта эшләүче руслар, татарларны да табут белән күмделәр. Зинһар, тәртип урнаштыра күрегез, – дип үтенде Тәлгат.

Шуннан соң гыйбадәтханә йортында Рәйсә абыстай мөселман кешесен кәфенләп күмү тәртибенә өйрәтә башлады.

– Зиратны тәртипкә салдык, хәләл ит белән туклану мәсьәләсен дә хәл итәсе иде, – диде Таһир хәзрәт. – Коръән ашы уздырганда итне кайдан аласыз?

– Хәләл итне авылдан алып киләбез. «Сайгатина» совхозы белән хезмәттәшлекне көйләп җибәрсәгез, бөтен халык рәхмәт әйтәчәк сезгә, хәзрәт, – диделәр Тәлгат белән Дамир.

Икенче көнне үк, Таһир хәзрәт «Сайгатина» совхозына барып, җитәкчесе белән очрашты. Хәләл итеп суйдыру тәртибен аңлатты. Бер атна эчендә бу эш җайга салынды. Үзенең кешесен алып барып суйдырды. Гыйбадәтханәгә суыткыч алып куелды. Мәҗлескә чакырып килүчеләрдән Рәйсә: «Хәләл итең бармы?» – дип кенә сорады, булмаса, үзе биреп җибәрде. Шулай итеп, мөселманнар хәләл ит белән туклана башлады.

Декабрь аенда Таһир хәзрәтне Хәмит Ясәвиев чакыртып алды. Якты йөз белән каршылады. Үзе дә аның каршына килеп утырды.

– Унике гаилә яши торган бараклар сүтеләчәк, мәчет өчен җир шул урыннан биреләчәк, - диде ул.

– Урыны әйбәт, ул баракларны кайчан сүтә башлыйлар?

– Сүтәргә шәхси эшмәкәрләр ярдәм итәчәк. Зур мәчет салганчы, башта кечкенәрәген салып карарга киңәш итәм, – диде Ясәвиев.

– Халык күп йөри башласа, зурайтырбыз.

1994 елның май аенда иске бараклар сүтелеп алынды. Сентябрьдә яңа мәчет төзелеше башланды. Таһир хәзрәт төзелешне финанслауда, Хәмит Ясәвиев булышлыгына таянды. Ярты елдан артык вакыт эчендә 12х12 метрлы мәчет бинасы сафка басты. 1995 елның 25 февралендә Сургут шәһәрендә тантаналы төстә мәчет ачылды. Татарстаннан килгән зур кунаклар арасында республиканың баш казые Габделхак хәзрәт Саматов та бар иде. Себер җиренә аяк баскан көненнән алып, динне торгызу юлында күпме сынаулар аша узган улын кочаклап алды.

– Сабыр иткән – морадына җиткән, улым. Дин ул – безнең тормышыбыз, яшәешебез, кыйблабыз! – диде.

Яңа мәчетнең беренче азанын да Камил әйтте.

– Сургут шәһәре киләчәккә зур адымнар белән атлый. Себер җирендә нефть компанияләре колачлы төзелешләр алып бара. Халык саны елдан-ел арта. Бу мәчет кенә мөселманнарның ихтыяҗын канәгатьләндерә алмаячак. Берничә елдан Россиядәге иң матур мәчет Сургутта булыр, дип ышанам, – диде Таһир хәзрәт, үзе күрергә теләгән мәчет белән мәдрәсәне күз алдына китереп.

–Амин, улым! Мин сиңа ышанам, – диде әтисе.

■ **Гөлсинә ГАЛИМУЛЛИНА**

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

«Азан» радиосын azan.fm сайтында яки «Азан» радиосы рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

**Сайт:** azan.fm
**Инстаграм:** azan.fm
**Вконтакте:** azanfm

**Телеграм-канал:** azanfm
**Почта:** radio@azan.fm
**Тел.:** 8 (843) 598-09-43

**ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ**

6:05 Коръән тәфсире
6:25 Көндәлек догалар
6:30 Тынычлык тәгълиматы
6:50 Сак булыгыз! Секталар!
7:05 Таян Аллаһка
7:20 Хәзрәткә сорау
7:30 Иман тәме
7:50 Миллият сүзлеге
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар
8:05 Бәхет тулы йорт
8:30 Күңелдән күңелгә
8:50 Шәхесләргә шәрехләр
9:00 Рухи хәзинә
9:15 Гыйбадәте Исламия
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
10:40 Миллият сүзлеге
10:45 Көндәлек догалар
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака
11:00 40 хәдис
11:30 Мәчетләребез тарихы
11:40 101 вәгазь
12:00 Азан
12:10 Гыйбадәте Исламия
12:25 Миллият сүзлеге
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт
14:10 Әхлак баскычлары
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы
14:45 Сөннәт юлы
15:05 Коръән тәфсире
15:25 Көндәлек догалар
15:30 Таян Аллаһка
15:45 Иман тәме
16:05 Миллият сүзлеге
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар
16:20 Бәхет тулы йорт
16:40 Күңелдән күңелгә
17:00 Шәхесләргә шәрехләр
17:10 Гыйбадәте Исламия
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака
17:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
18:00 101 вәгазь
18:20 Гыйбадәттә сәгадәт
18:30 Хәзрәткә сорау
18:40 Сөннәт юлы
19:40 Әдәбият күрке әдәп
19:55 Миллият сүзлеге
20:00 40 хәдис
20:30 Мәчетләребез тарихы
20:40 Нәниләргә нәсыйхәт
20:45 Пәйгамбәрләр тарихы
21:05 Һәр яхшы сүз – сәдака
21:15 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.)
21:50 Көндәлек догалар
22:00 Намаз дәресләре
22:20 Әхлак баскычлары
22:30 Миллият сүзлеге
23:00 Коръән

**ҖОМГА**

6:00 Җомга тәбриге
6:05 Коръән тәфсире
6:25 Көндәлек догалар
6:30 Тынычлык тәгълиматы
6:50 Сак булыгыз! Секталар!
7:05 Таян Аллаһка
7:20 Хәзрәткә сорау
7:30 Иман тәме
7:50 Миллият сүзлеге
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар
8:05 Бәхет тулы йорт
8:25 Җомга тәбриге
8:30 Күңелдән күңелгә
8:50 Шәхесләргә шәрехләр
9:00 Рухи хәзинә
9:15 Гыйбадәте Исламия
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
10:00 Җомга тәбриге
10:40 Миллият сүзлеге
10:45 Көндәлек догалар
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака
11:00, 20:00 40 хәдис
11:30 Мәчетләребез тарихы
11:40, 18:00 101 вәгазь
12:00 Азан
12:10 Гыйбадәте Исламия
12:25 Миллият сүзлеге
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт
14:10 Әхлак баскычлары
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы
14:45 Сөннәт юлы
15:00 Җомга тәбриге
15:05 Коръән тәфсире
15:25 Көндәлек догалар
15:30 Таян Аллаһка
15:45 Иман тәме
16:05 Миллият сүзлеге
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар
16:20 Бәхет тулы йорт
16:40 Күңелдән күңелгә
17:00 Шәхесләргә шәрехләр
17:10 Гыйбадәте Исламия
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака
17:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
18:20 Гыйбадәттә сәгадәт
18:30 Хәзрәткә сорау
18:40 Сөннәт юлы
19:40 Әдәбият күрке әдәп
19:55 Миллият сүзлеге
20:30 Мәчетләребез тарихы
20:40 Нәниләргә нәсыйхәт
20:45 Пәйгамбәрләр тарихы
21:05 Һәр яхшы сүз – сәдака
21:15 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.)
21:50 Көндәлек догалар
22:00 Намаз дәресләре
22:20 Әхлак баскычлары
22:30 Миллият сүзлеге
23:00 Коръән

**ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ**

6:05 Коръән тәфсире
6:25 Көндәлек догалар
6:30 Тынычлык тәгълиматы
6:50 Сак булыгыз! Секталар!
7:05 Таян Аллаһка
7:20 Хәзрәткә сорау
7:30 Иман тәме
7:50 Миллият сүзлеге
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар
8:05 Бәхет тулы йорт
8:30 Күңелдән күңелгә
8:50 Шәхесләргә шәрехләр
9:00 Рухи хәзинә
9:15 Гыйбадәте Исламия
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
10:40 Миллият сүзлеге
10:45 Көндәлек догалар
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака
11:00 40 хәдис
11:30 Мәчетләребез тарихы
11:40 101 вәгазь
12:00 Азан
12:10 Гыйбадәте Исламия
12:25 Миллият сүзлеге
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт
14:10 Әхлак баскычлары
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы
14:45 Сөннәт юлы
15:05 Коръән тәфсире
15:25 Көндәлек догалар
15:30 Таян Аллаһка
15:45 Иман тәме
16:05 Миллият сүзлеге
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар
16:20 Бәхет тулы йорт
16:40 Күңелдән күңелгә
17:00 Шәхесләргә шәрехләр
17:10 Гыйбадәте Исламия
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака
17:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
18:00 101 вәгазь
18:20 Гыйбадәттә сәгадәт
18:30 Хәзрәткә сорау
18:40 Сөннәт юлы
19:40 Әдәбият күрке әдәп
19:55 Миллият сүзлеге
20:00 40 хәдис
20:30 Мәчетләребез тарихы
20:40 Нәниләргә нәсыйхәт
20:45 Пәйгамбәрләр тарихы
21:05 Һәр яхшы сүз – сәдака
21:15 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.)
21:50 Көндәлек догалар
22:00 Намаз дәресләре
22:20 Әхлак баскычлары
22:30 Миллият сүзлеге
23:00 Коръән

# Казан өчен март аена намаз вакытлары

| Көн | Көн Исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/иф-тар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.03.2021 | Душ | 04:31 | 05:04 | 06:34 | 12:00 | 15:20 | 17:18 | 18:59 |
| 02.03.2021 | Сиш | 04:29 | 05:01 | 06:31 | 12:00 | 15:22 | 17:20 | 19:01 |
| 03.03.2021 | Чәрш | 04:26 | 04:59 | 06:29 | 12:00 | 15:24 | 17:22 | 19:03 |
| 04.03.2021 | Пәнҗ | 04:24 | 04:56 | 06:26 | 12:00 | 15:26 | 17:24 | 19:05 |
| 05.03.2021 | Җом | 04:21 | 04:54 | 06:24 | 12:00 | 15:28 | 17:26 | 19:07 |
| 06.03.2021 | Шим | 04:18 | 04:51 | 06:21 | 12:00 | 15:29 | 17:28 | 19:10 |
| 07.03.2021 | Якш | 04:16 | 04:49 | 06:19 | 12:00 | 15:31 | 17:30 | 19:12 |
| 08.03.2021 | Душ | 04:13 | 04:46 | 06:16 | 12:00 | 15:33 | 17:32 | 19:14 |
| 09.03.2021 | Сиш | 04:10 | 04:44 | 06:14 | 12:00 | 15:35 | 17:34 | 19:16 |
| 10.03.2021 | Чәрш | 04:07 | 04:41 | 06:11 | 12:00 | 15:36 | 17:36 | 19:18 |
| 11.03.2021 | Пәнҗ | 04:05 | 04:39 | 06:09 | 12:00 | 15:38 | 17:39 | 19:20 |
| 12.03.2021 | Җом | 04:02 | 04:36 | 06:06 | 12:00 | 15:40 | 17:41 | 19:23 |
| 13.03.2021 | Шим | 03:59 | 04:33 | 06:03 | 12:00 | 15:42 | 17:43 | 19:25 |
| 14.03.2021 | Якш | 03:56 | 04:31 | 06:01 | 12:00 | 15:43 | 17:45 | 19:27 |
| 15.03.2021 | Душ | 03:53 | 04:28 | 05:58 | 12:00 | 15:45 | 17:47 | 19:29 |
| 16.03.2021 | Сиш | 03:50 | 04:26 | 05:56 | 12:00 | 15:47 | 17:49 | 19:32 |
| 17.03.2021 | Чәрш | 03:47 | 04:23 | 05:53 | 12:00 | 15:48 | 17:51 | 19:34 |
| 18.03.2021 | Пәнҗ | 03:44 | 04:20 | 05:50 | 12:00 | 15:50 | 17:53 | 19:36 |
| 19.03.2021 | Җом | 03:41 | 04:18 | 05:48 | 12:00 | 15:52 | 17:55 | 19:38 |
| 20.03.2021 | Шим | 03:38 | 04:15 | 05:45 | 12:00 | 15:53 | 17:57 | 19:41 |
| 21.03.2021 | Якш | 03:35 | 04:12 | 05:42 | 12:00 | 15:55 | 17:59 | 19:43 |
| 22.03.2021 | Душ | 03:32 | 04:10 | 05:40 | 12:00 | 15:56 | 18:01 | 19:45 |
| 23.03.2021 | Сиш | 03:29 | 04:07 | 05:37 | 12:00 | 15:58 | 18:03 | 19:48 |
| 24.03.2021 | Чәрш | 03:26 | 04:05 | 05:35 | 12:00 | 16:00 | 18:05 | 19:50 |
| 25.03.2021 | Пәнҗ | 03:23 | 04:02 | 05:32 | 12:00 | 16:01 | 18:07 | 19:53 |
| 26.03.2021 | Җом | 03:19 | 03:59 | 05:29 | 12:00 | 16:03 | 18:09 | 19:55 |
| 27.03.2021 | Шим | 03:16 | 03:57 | 05:27 | 12:00 | 16:04 | 18:11 | 19:58 |
| 28.03.2021 | Якш | 03:13 | 03:54 | 05:24 | 12:00 | 16:06 | 18:13 | 20:00 |
| 29.03.2021 | Душ | 03:09 | 03:52 | 05:22 | 12:00 | 16:07 | 18:15 | 20:02 |
| 30.03.2021 | Сиш | 03:06 | 03:49 | 05:19 | 12:00 | 16:09 | 18:17 | 20:05 |
| 31.03.2021 | Чәрш | 03:03 | 03:46 | 05:16 | 12:00 | 16:10 | 18:19 | 20:08 |

10нчы марттан 11енә каршы төн – Мигъраҗ кичәсе / 27нче марттан 28енә каршы төн – Бәраәт кичәсе

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Февраль саны, №2 (307)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф.И.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДһӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2532
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170,04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 25 нче февральда таратыла.
График буенча бу санга 24 нче февраль көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.